«Тормышымда начар кешеләр очрамады»

Озын тормыш юлы узып, бүген бер үкенүләрсез көн итеп ятучы, пар канатлары белән иман күгендә тирбәлүче Флюра апа Кашаповалар өеннән мин бер хакыйкатькә инанып чыктым. Зар – зарланган саен арта, карасын күргән саен, дөнья караңгылана, кояш сүрәнләнә икән ул. Ә инде булганына риза булып, югын бар итәргә тырышып, шөкрана кылып хәләл яшәгәндә, гомер мәгънәле дә, ямьле дә, бәрәкәтле дә.

8 БИТ

Никах булсын гомерле

Абдулла хәзрәт ӘДҺӘМОВ:
–Гаиләдә баш кеше – ир-ат, мин монда командир дип гайрәтләнеп йөри беләләр, ә үз өсләренә җаваплылык аласылары килми. Әтинең балага калдырган иң зур мирасы – яхшы тәрбия. Без имамнар җомга вәгазьләрендә халыкка шуны төшендерергә тиешбез.

5 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Җомга | 27.01.2017 | № 8 (5770) www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

«АКЧА БЕРКАЙЧАН ДА ҖИТМИ, ӘММА РУХИ МИРАС МӨҺИМРӘК»

2010 елны, тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне яңадан торгызу максатыннан, Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев инициативасы белән «Яңарыш» фонды булдырылган иде. Шушы вакыт эчендә Болгар шәһәрчеге һәм Зөя утраучыгы сафка бастырылды. Казан Изге Ана иконасы соборының да, Болгар ислам академиясенең дә проектлары әзер инде. Исегезгә төшерәбез, Болгар шәһәрчеге ЮНЕСКО мәдәни мирасы исемлегенә дә кертелде. Минтимер Шәймиев әйтүенчә, хәзерге вакытта Зөя шәһәрчегендәге Успения соборын да Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертү өчен әзерлек эшләре алып барыла. Мондый статус алыр өчен мөмкинлекләребез зур, дип бәяли ул.

trophygames.ru

Зөһрә САДЫЙКОВА

– Әлеге эшләрне башлаган вакытта без: «Бу гамәлләр Россиянең рухи яктан яңаруына сигнал булырга тиеш», – дигән идек. Моның шулай икәнлегендә шик юк, чөнки рухи дөньядан башка җәмгыять үсеш кичерә алмый. Юбилеем алдыннан Россия Президенты Владимир Путин һәм Премьер-министр Дмитрий Медведев белән очрашуым турында барыгыз да белә инде. Бу өлкәдә нилләр эшләнүе турында сөйләгәч, Владимир Владимирович, хезмәтне югары бәяләп: «Бу – бик мөһим эш, бәлки, без шөгыльләнергә тиешле иң мөһим эшләрнең берседер», – диде. Мондый эшләрне артык планга калдырырга кирәкми. Акча бервакытта да җитми ул, әмма рухи дөньядан да мөһимрәк нәрсә була алмый. Шуңа күрә үземнән дә, Татарстан Президенты Рөстәм Нургалиевич исеменнән дә барыгызга рәхмәт әйтәм. Без ашыкмыйча эшлибез, чөнки эш-гамәлләребезнең киләчәк буыннарга да озак еллар хезмәт итүен телибез, – диде кичә «Яңарыш» фондының попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиев Хәйриячеләр китабының җиденче томын тапшыру тантанасында.

Минтимер Шәймиев әйтүенчә, бик күп акчалар таләп итәлә торган эшләр эшләнелгән инде, киләчәккә дә зур планнар төзелгән.

Хәйриячеләр китабының җиденче томына 20 мең хәйриячененң исеме кертелгән. Башкаларыннан аермалы буларак, моныңсы өч бүлектән тора: Болгар музей-тыюлыгын һәм Зөя утрау-шәһәрчеген торгызуга ярдәм иткән хәйриячеләр (җиде мең); Болгар ислам академиясен төзүгә үз өлешләрен кертүчеләр (җиде мең); Казан Изге Ана иконасы соборын торгызуда булышучылар.

Хәйриячеләрнең күбесе китапларга өч-биш тапкыр кертелгән. Кайберләренең исемнәре хәтта барлык томнарда да мәңгеләштерелгән. Шулай ук хәйрия эшләрендә гаиләләре белән бергәләп катнашучылар да бар. Шундыйлардан – нефть сәнәгате мәсьәләләре буенча Татарстан Президенты ярдәмчесе Шәфәгать Тәхәутдинов гаиләсе. Ә Спас районында яшәүче Марина Хрусталева исә игелекле эшләрдә 14 яшьлек кызы һәм 7 яшьлек инвалид улы белән бергәләп катнашкан.

Минтимер Шәймиев әйтүенчә, «Яңарыш» фонды борынгы Болгар һәм Зөя утрау-шәһәрчекләрен төзекләндерү белән беррәттән, Казан Кремленә дә игътибарын юнәлтәчәк. Тиздән биредә яңарту эшләре башланачак.

– Казан Кремле ЮНЕСКО мәдәни мирасы исемлегенә кертелүгә дистә елдан артык вакыт узды. Без проблемалар башлануын көтеп утыра алмыйбыз. Бу бик «нечкә» эш, әмма әлегә без, ни генә эшләсәк тә, ЮНЕСКО тарафыннан югары бәя генә алабыз, – диде Минтимер Шәймиев.

Татарстанның иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре ачыкланды

Казан Ратушасында «Татарстанның иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» бәйгесенә йомгак ясалды. Һәм «Россиянең 100 иң яхшы товары» программасы җиңүчеләрен билгеләделәр.

Зөһрә САДЫЙКОВА

«Россиянең 100 иң яхшы товары» федераль программасы 19 ел дәвамында уңышлы эшләп килә һәм уздырыла торган бәйгеләр арасында ул зур әһәмияткә ия. Татарстанда җитештерелгән товарларның иң яхшыларын 50дән артык белгеч катнашындагы жюри сайлап ала.

– Күп еллар дәвамында Россия субъектлары арасында Татарстан бу өлкәдә әйдәп баручылар рәтендә тора. 2004 елда федераль программаның төбәк этабы башланганнан бирле, «Татарстанның иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» бәйгесендә 2,5 мең оешма катнашты. Алар биш мең төрле исемдәге продукция һәм хезмәт тәкъдим итте. Федераль этапка аларның 1,5 меңе чыгарылды. Шуларның 600е лауреат исеменә лаек булды. Әлеге бәйге оешмаларда җитештерелгән продукциянең һәм хезмәтнең көндәшлек сәләтен арттыра, җитештерү эшенең камилләшүенә китерә, аларны яңа технологияләр куллана башлауга этәрә, – диде Татарстан Премьер-министры Илдар Халиков тантана ачылышында.

Илдар Халиков әйтүенчә, бәйгедә катнашучыларның саны да арта, географиясе дә киңәя. Оешмаларның 70 проценты ел саен катнаша, 30 проценты – яңалар. Бәйгедә катнашырга теләк белдерүчеләр саны елдан-ел арта. 2004 елда 242 гариза тапшырылган булса, 2016 елда аларның саны 447гә җиткән. Шунысы да бар, кече һәм урта эшмәкәрлек белән шөгыльләнүчеләр арасында да бәйге бик популяр. 2016 елда, мәсәлән, алар барлык катнашучыларның 40 процентын тәшкил иткән.

Татарстан сәнәгать һәм сәүдә министры Альберт Кәримов тә:

– Бәйгенең максаты – республика предприятиеләрендә җитештерелә торган продукциянең һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын арттыру һәм көндәшлеккә сәләтне үстерү, – дип басым ясады, бәйгедә җиңүчеләрне һәм катнашучыларны котлап.

tatar-inform.ru

«Россиянең 100 иң яхшы товары», «Инновация-2016» программасы карары нигезендә инновацион эшчәнлекне үстергән өчен, «ТАИФ-НК» ААҖ бүләкләнде. Моннан кала «Татарстанның сыйфат лидеры» призына – «Производство-техник билгеләнешле продукция» номинациясендә – «Түбән Кама нефтехим», «Халык өчен сәнәгать товарлары» номинациясендә – «Алсу» Әлмәт оек фабрикасы» ачык акционерлык җәмгыяте, «Азык-төлек» номинациясендә – «Майский» теплица комбинаты, «Хезмәт» номинациясендә Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе, «Халык һөнәрчеләре эшләнмәләре» номинациясендә Мәдинә Мәхмүтова бәйгенең иң югары бүләгенә ия булдылар.

Юл кадерен белмибез

Илдар Мөхәммәтҗанов фотоархивыннан

Быелга республикада юллар төзү һәм төзекләндерү эшләренә төрле бюджет чыганакларыннан 11,7 миллиард сум билгеләнгән.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Министрлар Кабинетында юллар төзелешенә кагылышлы киңәшмәдә: «Юлларда кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч яный торган авыр хәлләр булмасын. Иң мөһиме – юлларны карап тоту. Бигрәк тә кышын бу мәсьәләгә аеруча җитди карарга кирәк», – дигән иде.

Юл газабы – гүр газабы, дигән борынгылар. Мин үзем дә заманында бата-чума әллә ничә чакрымнарны җәяү йөргән кеше. Хәзер дә республикада күп авылларга асфальт юллар кермәгән әле. Саз еруның нәрсә икәнлеген яхшы белә андый авылларда яшәүчеләр. Шөкер, Балык Бистәсе районында юллар төзелеше буенча зур эшләр башкарылды. Туган авылым Күкигә, күршедәге Ямаш белән Балтач авылларына да асфальт юллар тоташты. Шушы авыллар арасындагы «юлларда» тәгәрмәчле трактор яртылаш бата торган чокырлар бар иде бит. Бүген җиңел автомобильләрдә җырлый-җырлый җилдерәбез. Кыш көне дә батып калу юк. Юл хуҗалыгы машиналары төнлә дә, иртән дә карны чистартып узалар. Язгы якларда юл эшчеләре авылларга килеп, кар сулары агу өчен ерганаклар казып йөри хәтта. Ни кызганыч, ир-егетләре булган шәхси хуҗалыкларның кайберләре өйләре каршындагы асфальт юл читенә су ерганагы казымый. Кар-яңгыр сулары юл өстеннән ага, шул сәбәпле асфальт яргалана. Юл кадерен белмибез. Бу сүзләремә, бәлки, кайберәүләр: «Үзең казы!» – дияр. Казыйм. Капка төбенә генә түгел, урамдагы чокырларга вак таш та бушатам әле. Йөк машинасында китертерлек акча юк, чиләк белән ташыйм. Хатын: «Җиңел автомобильдә дөньяда бер син генә таш ташыйсыңдыр», – ди. Йортларда икешәр-өчәр машина хәзер, һәр кеше бер чиләк кенә алып кайтса да, ныклы юл өслеге барлыкка киләчәк. Татарстан Президенты да әнә: «Иң мөһиме – юлларны карап тоту» – ди бит.

Янә акчага әйләнеп кайтсак, «Куркынычсыз юллар» проекты кысаларында, Татарстанга 1 миллиард 825 миллион сум Россия хөкүмәтеннән бирелгән. Проектны «Бердәм Россия» сәяси партиясе әзерләгән. Татарстанда бу җәйдә 31 000 бакчачылык ширкәтен сөенеч көтә. Республиканың транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары Артем Чукин әйткәнчә, бакчачылык ширкәтләренә асфальт юллар сузылачак, әлеге эшләрне башкарырга республика бюджетында 300 миллион сум каралган.

Татарстанда автомобиль юлларының гомуми озынлыгы – 38 111 километр. Шуның 1 064 километры – федераль, ә 13 380 километры – төбәк әһәмиятендәгеләр. Җирле кулланылыштагы юллар – 23 667 километр.

Дамир БӘДРИЕВ.

Юныс Әхмәтҗановны искә алып

27-28 февраль көннәрендә Казанда татар милли аш-су остасы Юныс Әхмәтҗанов исемендәге бәйге үтәчәк, дип хәбәр итә «Татар-информ». Анда аш-су пешерүчеләр милли ризыкларны әзерләү буенча һөнәри осталыкта ярышачак. Бәйге Казан һәм Татарстанның Рестораторлар һәм отельерлар ассоциациясе тарафыннан Бөтендөнья татар конгрессы, Казан мэриясе белән берлектә оештырыла. Чараның максаты – бүгенге чорда татар милли аш-суының сыйфатын күтәрү, популярлаштыру.

Бәйге Ленин һәм Халыклар Дуслыгы ордены бүләкләре лауреаты, татар кулинариясе буенча бик күп китаплар авторы Юныс Әхмәтҗановның туууына 90 ел тулуга багышлана.

Хәйрия концерты булачак

29 гыйнварда Татарстан халыклары дуслыгы йортында хәйрия концерты узачак. Чарадан кергән акча Казан Мәрьям Ана иконасы соборы төзелешенә тотылачак.

Чара 16.00 сәгатьтә башлана. Билет бәясе (хәйрия максатында) – 100 сум. Билетларны Татарстан халыклары дуслыгы йортында концерт көнендә алырга мөмкин, дип хәбәр итә Казан мэриясе сайты, Казан епархиясе матбугат хезмәтенә сылтама белән.

Лаешта өй туйлары

Шушы көннәрдә Лаеш районының Габишево бистәсендә өй туйлары гөрләде. Бирелә биш катлы ике йорт куллануга тапшырылды. Кулларына фатир ачкычын алган 28 гаиләнең бишесе – Бөек Ватан сугышы ветераннарының толлары, 19ы – социаль ипотека программасында катнашучылар, ә дүртесе – «Яратель» кош фабрикасында эшләүчеләр.

Бәхетлеләрне өй туе белән Лаеш районы башлыгы Михаил Афанасьев, «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең директорлар советы рәисе Ришат Хисмәтуллин һәм «Төзүче» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең генераль директоры Ленар Григорьев котлады.

– Бу – район тормышында зур вакыйга. Киләчәктә Габишево бистәсендә заманча инфраструктуралы, уңайлы булган тулы бер микрорайон төзергә планлаштырыла, – дип сөендерде бистә халкын район башлыгы Михаил Афанасьев.

Ришат Хисмәтуллин исә яңа фатирларга күченүчеләргә бәхетле тормыш теләде.

– Йортларда балаларның шат авазы яңгырап торсын иде. Матур урын, уңайлы торак һәм заманча инфраструктура – гаиләләр бәхетле булсын өчен бөтен шартлар да тудырылган, – диде ул.

Фатир хуҗалары кунаклар кулыннан ачкыч алгач, матур гадәт буенча, кызыл тасманы кистеләр. Бу җаваплы эшне исә йортта яшәячәк балаларга тапшырдылар.

– Без яңа фатирыбызга күченүне бик озак көттек. Бу көннең килеп җитүенә әле һаман да ышанып бетә алмыйбыз. Менә иң элек фатирга песиебезне кертәбез, – дип, сөенече белән уртаклашты Альбина Шишолина.

Шунысын да искәртеп узарга кирәк, Лаеш республикада торак төзелеше актив алып барыла торган районнар рәтендә тора.

Тележурналистлар җыелды

Кичә «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең конференцияләр залында «Төбәк телевидениесе яңалыклары» дип аталган семинар узды. Бирелә Татарстанның төрле районнарында, шәһәрләрдә эшләп килүче телеканаллардан журналистлар җыелган иде. Аларга яңалыкларны әзерләүдә иң тәҗрибәле саналган «Татарстан 24» телеканалы белгечләре: телеканалның генераль директоры Сергей Лобов, яңалыклар хезмәте директоры Алексей Кулешов һәм башкалар мастер-класслар күрсәтте, тәҗрибә уртаклашты.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенә 19 телеканал керә. Түбән Кама, Чаллы, Әлмәт шәһәрләрендә, башка районнардагы телекомпанияләр көндәшлеккә сәләтле, зур тарихлы үзәкләр булып санала.

– «Татарстан 24» каналының төп концепциясе – сәгать саен яңалыклар тапшыру. Без мәгълүматларны бөтен Татарстан буенча, төбәкләрдән дә туплыйбыз. Бу эштә безгә, әлбәттә, республиканың төрле шәһәрләрендә, районнарында эшли торган телевизион үзәкләрдәге коллегаларыбыз ярдәм итә. Элек тапшырулар әзерләгәндә, кассетага яздырылган мәгълүматларны районнардан автобуслар аша тапшырырга туры килә иде. Бу, үз чиратында, оперативлыкны киметә. Хәзер тиз эшләү өчен барлык техник мөмкинлекләр дә тудырылган. Бүген семинарга җыелган коллегаларыбыз яңалыкларны начар эшли димим, алар аны башкача, үзләренчә әзерли. «Татарстан 24» – төбәк телеканаллары өчен коткаручы кебек. Бергә эшләү тапшыруны тагын да мәгълүматлырак итәчәк, баетачак. Бүген семинар барышында сыйфатлы сюжет әзерләүнең стандартларын булдырырга тиешбез. Универсаль продукт тудыру – уртак бурычыбыз. Шуңа да мондый очрашулар һәр ике-өч ай саен узар дип ниятлибез, – ди «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Андрей Кузьмин.

Семинарның башында «Эфир» компанияләр төркеме генераль продюсеры, директорлар советының генераль директоры Алексей Усанов «Татарстан 24» телеканалы турында тулырак сөйләде. Билгеле булганча, «Татарстан 24» «КЗН» һәм «Эфир 24» каналлары кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Фәнни, күңел ачу, сәламәтлек, башка өлкәләрне үз эченә алган тапшырулардан тыш, телеканалның төп максаты – сәгать саен халыкка яңа хәбәрләр тапшыру. Канал бер көн дә ял итми. Тиздән «Татарстан 24» телеканалын бар җирдә дә бердәй, телевизор пультындагы 22нче кнопкага басқач карап булырлык итеп көйләргә җыеналар. Бу хакта кабель операторлары белән сөйләшүләр алып барыла.

Эльвира МОЗАФФАР.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Андрей Кузьмин әйтүенчә, 7 февральдә Яшел Үзәндә «Татарстан 24» телеканалының беренче филиалын ачарга җыеналар.

Ялган аракы сатучыны «сатып» акча эшләгән

Республикада узган ел законсыз әйләнештән 450 мең литр ялган аракы алынган. Бу, 2015 ел белән чагыштырганда, 15 процентка артыграк, дип хәбәр иттеләр Татарстан дәүләт алкоголь инспекциясенең еллык коллегиясендә.

2 меңнән артык ялган аракы җитештерүчеләрне барлыгы 27 миллион сумнан артык штрафка тартканнар. Спиртлы эчемлекләргә килгәндә, бу өлкәдә закон бозучылар белән Татарстанның Эчке эшләр министрлыгы да көрәшә. Былтыр алар суррогат алкоголь җитештерү белән шөгыльләнгән ун зур каналны яба алганнар. Ялган аракы күләме артса да, быел соңгы ун ел эчендә Татарстанда беренче тапкыр суррогат спиртлы эчемлекләр белән көчле агулану очраклары теркәлмәгән.

– Былтыр республикада аракыдан 776 кеше зыян күргән, алар арасында 36 бала да бар. 267 очрак үлем белән тәмамланган, – ди Роспотребнадзорның Татарстан идарәсе җитәкчесе Марина Патяшина.

Сүз уңаеннан, законсыз рәвештәге алкоголь сату белән хәзер дәүләт органнары гына түгел, халык үзе дә көрәшә ала.

Татарстанның «Халык контроле» порталына этил спирты, алкоголь һәм составында спирт булган продукцияне җитештерү, аның әйләнешенә кагылышлы законнарны бозу турында мәгълүмат җибәрергә була. Килгән фактлар буенча башта тикшерү эшләре уздырыла. Мәгълүматларда күрсәтелгән фактлар чыннан да дөреслеккә туры килгән очракта, Татарстанның Дәүләт алкоголь инспекциясе мәгълүмат хуҗасына акча түли. Шул рәвешле Казанда берәү 56 мең сум акча эшләгән. Ул «Халык контроле»нә ялган аракы җитештерүчеләр турында 30дан артык хәбәр юллаган. Чаллыда яшәүче икенче берәү, 23 мөрәҗәгать җибәреп, 28 мең сум акча алган. Өченче урында – түбәнкамалы тугыз хәбәр өчен 19 мең сум белән бүләкләнгән.

Алкоголь базарында закон бозулар хакында хәбәрләр юллаган кешеләргә материаль ярдәм күрсәтү турындагы карарны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кабул иткән, бу максатларда ул 1 миллион сум акча да бүлеп биргән.

Әлеге эш уңышлы нәтиҗәләр бирә. Әйтик, 2015 елда барлыгы 108 генә хәбәр теркәлгән булса, Дәүләт инспекциясенең алкоголь продукциясе, этил спиртының сыйфаты, әйләнеше һәм җитештерүне дәүләт күзәтүе белән тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча җитәкчесе Игорь Марченко әйтүенчә, 2016 елда 28 муниципаль берәмлектән 625 хәбәр кабул ителгән.

Ялган аракы җитештерүчеләр белән көрәш юлында әлеге алымны Татарстан премьер-министры Илдар Халиков та хуплый.

– Шундый изге эшләр кылып, моның өчен бүләк тә алырга була әле, – дип, татарстанлыларга рәхмәтен белдерде ул коллегия барышында.

Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясенең «кайнар элемтә» телефонына 2016 елда 376 мөрәҗәгать кабул ителгән. Халык лицензиясез аракы, төнге сәгатьләрдә спиртлы эчемлекләр сату һәм башка тәртип бозулар турында хәбәр итә. Тикшерелгәннән соң, бу шикаятьләрнең 25 проценты дөреслеккә туры килгән.

«Максатыбыз: яхшы белгечләр әзерләү»

1-3 февраль көннәрендә республикада «WorldSkills» эшче һөнәрләр чемпионатының «Яшь профессионаллар» дигән төбәк этабы узачак. Бирегә 18-23 яшьлек егетләр һәм кызлар һөнәри осталыкта көч сынаша.

Алисә САБИРОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

НӘРСӘ СОҢ УЛ «WORLDSKILLS»?

«WorldSkills» – эшче һөнәрләрне популярлаштыру максатыннан булдырылган дөнья чемпионаты. Аны икенче төрле «Эшче куллар олимпиадасы» дип тә йөртәләр. Чемпионатка 1953 елда нигез салына. Икенче Бөтендөнья сугышыннан соңгы чорда дөньяда эшче һөнәрләренә кытлык булуы белән бәйле була ул. Иң беренче чемпионат Испаниядә уза. Соңыннан аңа Португалия, Германия, Бөекбритания, Франция, Марокко, Швейцария кушыла. Бүген 76 ил катнаша «WorldSkills» хәрәкәтендә.

Россиядә ил күләмендәге беренче чемпионат 2013 елда Тольятти шәһәрендә үткәрелә. Нәтиҗәдә иң яхшы студентлардан Россия җыелма командасы туплана. Безнекеләр үзләрен беренче тапкыр дөнья чемпионатында шул ук елны Германиядә сынап карый. Команда иң соңгы 41нче урында була. 2015 елда исә безнекеләр Сан-Паулу шәһәрендә ярышып, 14нче урынга менә һәм алты «һөнәри осталык өчен» медаленә лаек була.

«WorldSkills International» дөнья чемпионаты елына ике тапкыр гына оештырыла. Республикада узган төбәк этабыннан соң безнекеләр быел 15 март–3 апрель көннәрендә федераль округлар буенча ярымфиналда катнашачак. Ярыш 57 компетенция буенча барачак. Республика интерьер дизайны һәм осетин пироглары пешерү белгечлегеннән тыш, барлык компетенциядә дә көч сынашачак. 16-19 майда исә «WorldSkills Russia» илкүләм ярышлары башлана. Бу уңайдан халыкара чемпионатка илнең җыелма командасы туплана. «WorldSkills International» дөнья чемпионатының финалы Абу-Даби шәһәрендә октябрь аенда узачак.

КАРЬЕРА ҮСЕШЕ

Республика чемпионаты Казан ярминкәсе, Казан төзелеш көллияте, Казан мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумы базасында уза. Ярышларга Россиянең башка төбәкләреннән килгән экспертлар да катнаша. Алар республика командасы әзерлегенә бәя бирәчәк.

– Республика «WorldSkills»ның төбәк этабын инде бишенче тапкыр оештыра. Ярышларга узган елның октябрь-ноябрь айларыннан ук әзерләнә башладык. Һөнәри белем бирү учреждениеләренең һәр уныннчы студенты «WorldSkills»ның сайлап алу турында үз көчен сынап карады. 6000 укучы арасыннан күрсәткечләре иң яхшы булган 420 баланы сайлап алдык. Алар республика этабында 72 компетенция буенча көч сынашачак, – диде Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары Тимерхан Алишев.

Ярышта катнашучылар Универсиада авылында яшәячәк. Җиңүчеләр, спортчылар кебек үк, пьедесталга менәчәк һәм аларга медальләр тапшырачаклар. Халыкара чемпионатта җиңгән студент исә дөньяның иң зур оешмасы белән контракт төзи ала. Мәсәлән, 2014 елда Россиягә беренче алтын медаль китергән Татарстан егете Антон Лоскутов белән «Samsung» оешмасы кызыксынды. Хәзер исә ул Кореяда берьеллык стажировкада. Абу-Даби шәһәрендә узачак чемпионатта да ил данын ул яклаячак. Бер яктан, студентларга бу карьера баскычы буйлап үсеш булса, икенче яктан, акыллы башларның республикадан читкә китү куркынычы яный. Шуңа да хәзер белгечләрне үзебездә калдыру юнәлешендә саллы эш алып барыла. «WorldSkills» ярышларында үзен сынаган яшьләр илнең иң зур оешмаларында эшли ала. Үз уку йортында чемпионатның эксперты булу мөмкинлеге дә бар.

Республикада «WorldSkills» чемпионатын үткәрергә предприятиеләр дә актив ярдәм итә. Алар материал, кирәкле эш кораллары, җиһазлар белән тәэмин итә.

– Оешмалар чемпионатның сыйфатлы белгечләр әзерләргә сәләтле икәненә ышана, шуңа да яшьләргә һөнәри осталыкларын үстерүгә ярдәм итә, – диде Тимерхан Алишев.

Быел Россия җыелма командасының 35 компетенция буенча медаль алу мөмкинлеге бар.

– Кайсы һөнәр буенча җиңү яулаячагыбызны төгәл генә әйтеп булмый. Швейцариядән, мәсәлән, һич көтмәгәндә, биш медаль алып кайттык. Суыткыч техникасы, IT-технологияләр, мобиль робот техникасы, флористика, кунакханә белән идарә итү, медицина һәм социаль хезмәт күрсәтү кебек белгечлекләр безгә җиңү китерергә тиеш. Республика командасында сәләтләре әле ачылмаган яшьләр дә бардыр, – диде һөнәри компетенция үсеш үзәге директоры Эмиль Гобәйдуллин.

БАЛАЛАР ДА ЯРЫША

«WorldSkills»ның «Яшь профессионаллар» төбәк чемпионаты кысаларында шулай ук 10-17 яшьлек балалар өчен «JuniorSkills» ярышлары да оештырыла. Бирегә мәктәп укучылары үзләрен аэрокосмик инженерия, мерчендайзинг, металл кою кебек һөнәр буенча сынап карый ала. Ярышларда 572 бала катнаша. Чемпионат мәйданчыклары буйлап мәктәп укучылары өчен экскурсия оештыралар.

– Балалар да олылар белән бертигез дәрәҗәдә ярыша: мәйдан да, эш кораллары да шул ук. Безнең өчен бу – яшьләргә һөнәри ориентация бирү чарасы. Максатыбыз 2019 елга Казанда узачак ярышларга чемпионнар әзерләү генә түгел, ә республика икътисадына, предприятиеләренә яхшы белгечләр туплау да әле. Бу максат 2019 елдан соң да үзгәрешсез калачак, – диде Эмиль Гобәйдуллин.

– Кеше үз эшенең остасы булырга мөмкин, ләкин дөньякүләм зур ярышларда уңышка ирешү өчен бу гына җитми. Эшне вакытында төгәлләргә, сиңа карап торган меңләгән күзгә игътибар итмәскә, стрессларга бирешмәскә кирәк. «JuniorSkills» нәкъ менә шул сыйфатларны булдырырга ярдәм итә дә инде. Командада эшли белергә, инглиз телен камил үзләштерергә кирәк, – диде Тимерхан Алишев.

КЫЗЫКЛЫ ФАКТЛАР

Кореяда «WorldSkills» чемпионатында җиңгән кеше армия хезмәтеннән азат ителә.

2019 елда «WorldSkills» чемпионатын кабул итү өчен KAZAN EXPO-WorldSkills Arena бинасы төзелә. Аның гомуми мәйданы 169 мең квадрат метр булачак. Әлеге комплекс Лаеш районында «Казан» халыкара аэропорты янында урнашачак.

КЕЧЕ БИЗНЕС ҺӘМ ЭШМӘКӘРЛЕК КӨЛЛИЯТЕ

«WorldSkills» юнәлешендә булган эшмәкәрлек компетенциясе буенча да республика инде өченче ел белгечләр әзерли. Дәресләр Казанның кече бизнес һәм эшмәкәрлек көллиятендә бара.

– Төбәк этабына балаларны инде сентябрь аеннан җыябыз. Безнең үзәктә биш югары уку йорты һәм ун көллияттән 20 студент әзерләнә. Бирегә балалар бизнеска кагылышлы төрле биремнәр чишә, инглиз телен өйрәнә, – диде Кече бизнес һәм эшмәкәрлек көллияте директоры, Татарстан Республикасының эшмәкәрлек буенча махсуслашкан компетенция үзәге җитәкчесе Ольга Силантьева.

Көллиятнең үз укучыларыннан кала Казан Федераль университеты, Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты, Казан милли тикшеренү технология институты (КХТИ), Сәүдә-икътисад көллияте, Халыкара сервис көллияте студентлары WorldSkills таләпләре буенча бирегә белем ала.

Нинди өлкәдә бизнес үстерәчәкләрен укучылар бары ярыш алдыннан гына белә. Өч көн дәвамында алар бизнес-план төзи һәм аны жюри әгъзаларына тәкъдим итә.

– Безнең укучылар үзләрен генә түгел, башкаларны да эш белән тәэмин итәргә сәләтле булырга тиеш. Көллияттә без бизнес идеяләрне үстерү, финанс күрсәткечләрен арттыру, маркетинг тикшеренүләре үткәрү, аудиторияне өйрәнү кебек алымнар үзләштерәбез, – диде көллиятнең уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары Татьяна Адриянова.

Республика командасы эшмәкәрлек компетенциясе буенча үткән ел Мәскәүдә узган милли чемпионатта «Үз эшенең остасы» медаленә ия булган.

КАЗАН ТӨЗЕЛЕШ КӨЛЛИЯТЕ

Казан төзелеш көллияте плитә ябыштыру, түбә ябу, кирпеч салу, таш шомартучы, ландшафт дизайны кебек биш компетенция буенча белгечләр әзерли. Көллият аеруча да кирпеч салу эшләренә басым ясый. Узган ел көллият студентлары Ислам Гайнуллин әлеге юнәлештә чемпионатның төбәк этабында – III урын, ә Тәлгать Сәмигуллин Идел буе Федераль округы буенча I урын ала. Хәзер Ислам «WorldSkills» чемпионатының төбәк этабына әзерләнсә, Тәлгать инде көллиятнең башка студентларына һөнәри белем бирә.

– Без, әлбәттә, ярышларга җиңү өчен барабыз. Ләкин көндәшләребез дә бар. Мари Эл республикасы, Краснодар крае, Төмән шәһәреннән катнашучылар көчле. Россия буенча күп йөрим. Мәскәү, Волгоград, Оренбург якларындагы уку йортларында кирпеч салу белгечлегенә ихтыяҗ юк. Безнең көллияткә укырга кергәндә хәтта конкурс бар. Минемчә, бу һөнәрнең популярлашуына «WorldSkills» сәбәпче, – диде көллиятнең директор урынбасары Ирина Захарова.

Узган 2016 елда республикада 25 778 пар язылышкан. Үткән ел белән чагыштырганда, бу саннар 15,7 процентка кимрәк. Аерылышучылар саны исә 2015 ел дәрәҗәсендә калган – барысы 13 450 гаилә таркалган. Әлеге саннар тагын да күбрәк булырга мөмкин иде. Ни өчен дигәндә, ЗАГС идарәсе аерылышу бусагасында торган гаилә парлары өчен «Гаиләне саклап калабыз» дигән яңа проект эшләтеп җибәрде. Проект аерылышуларны профилактикалау һәм гаиләне саклап калуга юнәлдерелгән. Психологлар аерылышырга дип килгән һәр гаилә белән сөйләшүләр уздыра. Нәтиҗәдә 519 парның 364е аерылудан баш тарткан.

Никах булсын гомерле

dumrt.ru

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

ЯҢА ӘЙБЕР УЙЛАП ЧЫГАРЫРГА КИРӘКМИ

Гаилә кыйммәтләрен саклап калу буенча республикада төрле чаралар уздырылып килә. Әлеге эштә Татарстан Мөселманнары диния нәзарәте дә читтә калмый. Аерым алганда, Казанның «Гаилә» мәчете гаилә проблемаларына багышланган лекцияләр, түгәрәк өстәлләрне һәрдаим уздыра. Шушы көннәрдә генә мәчет «Гаиләдәге мәсьәләләр һәм аларны чишү юллары» дип аталган түгәрәк өстәл уздырды. Аны Татарстан мөфтие урынбасары, «Гаилә» мәчете имам хатибы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин алып барды. Түгәрәк өстәлгә Татарстан Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге директоры Флюра Илдарханова да чакырылган иде. Аның сүзләренчә, гаиләне саклап калу буенча яңа методикалар уйлап чыгарырга кирәкми. Әби-бабаларыбыз тәрбиясен искә төшерү, татар мәгърифәтчеләренең хезмәтләре белән танышу да җитә.

– Никахта биш ел да яши алмаучы парлар күп. Соңгы вакытта исә 50 яшьтән узып киткән ирле-хатыннар арасында да аерылышучылар артты. Традицион гаилә кыйммәтләрен саклауга игътибарны арттырырга кирәк. Мин кечкенә чагымда авылга әби янына кайта идем. Аның янында армиядән кайтып комбайда эшли башлаган абыем да яшәде. Ул эштән кайткач, әби миңа комган тоттыра да, абыеңа юынырга булыш, дия иде. Абый кайткач кына кичке аш ашарга утырабыз. Шушы гади генә тәрбия чарасы аша әби өйдәге ир-атка карата хөрмәт тәрбияләде. Хатын өстендә ир хакы булган кебек, ир өстендә дә хатын хаклары бар. Никах каршындагы җаваплылыкны аңламау аерылышуга китерә, – дип сөйләде ул.

Шунысы сөенечле: Гаилә һәм демография үзәге оештырган социологик тикшеренүләрдән күренгәнчә, соңгы елларда диннең көчәеп китүе нәтиҗәсендә моноэтник гаиләләрнең саны арткан. Татар – татар, рус рус милләтеннән булган кеше белән гаилә кора.

Флюра Илдарханова үзәкнең татар мәгърифәтчеләре хезмәтләрен өйрәнүен дә билгеләп үтте.

– Гаилә проблемаларын ничек хәл иткәннәр икән дип, аларның хезмәтләренә мөрәҗәгать иттек. Мәгърифәтчеләрнең фикерләре тупланган «Гаилә – милләт нигезе» исемле китап чыгардык. Анда аларның гаиләдә тәрбия өлкәсендә һәркем кулланырлык искиткеч кыйммәтле фикерләр урын алды. Каюм Насыйриның әдәп-әхлак, тәрбия кылу турындагы үгет-нәсыйхәтләрен татар, рус, инглиз телендә чыгардык.Ниндидер программалар төзегән булабыз, менә шушындый хезмәтләрне без өлге итеп алырга тиеш, – диде ул.

Киләчәктә Гаилә һәм демография үзәге татар хатын-кызлары мәгърифәтчеләренең дә хезмәтләрен нәшер итәргә уйлый. Флюра Илдарханова, гаиләнең дәрәҗәсен күтәрү, гаилә кыйммәтләрен саклау максатыннан, матбугат чараларында уңышлы матур тулы гаиләләр турындагы позитив язмаларны күбрәк күрергә теләвен дә белдерде.

ГАИЛӘ КЫЙММӘТЛӘРЕН САКЛАУДА ӨЛКӘН БУЫННЫҢ РОЛЕ ЗУР

Түгәрәк өстәлдә катнашкан Бөтендөнья татар конгрессы каршындагы татар яшьләре форумы җитәкчесе Тәбрис Яруллин сүзләренчә, хәзерге яшь гаиләләрнең әби-бабайлары белән генә түгел, әти-әниләреннән дә аерым яшиселәре килә.

– Үз фатирларын булдырырга тырышалар. Бер йортта бер гаилә булып яшәү күренеше бетеп бара. Шул рәвешле, туганнар арасында үзара аралашу бетә, балаларга әби-бабай тәрбиясе җитеп бетми. Әдини тәрбияне нәкъ менә алар бирә, догаларны алар өйрәтә бит, – ди ул.

Тәбрис Яруллин фикеренчә, гаиләләрне саклап калу, бала тәрбияләүдә мәгърифәтчеләрнең хезмәтләренә генә таяну җитми, яңа алымнар эзләргә кирәк.

– Гап-гади мисал: смартфоннан баланы ничек арындырырга? Хәзерге балалар смартфоннары белән яхшырак беләләр. Чит телләрне өйрәнгәндә үз теленне ничек камил белергә? Моның ише сораулар бик күп. Бала тәрбияләүдә заманча кызыклы методикалар шактый. Без аларны өйрәнеп, үзебезгә яраклаштырырга тиеш, – ди ул.

АТАНЫҢ СҮЗЕ – АКЫЛНЫҢ ҮЗЕ

175нче мәктәпнең «Әтиләр шурасы» рәисе Нияз Шакиров үзенең чыгышында балаларны тәрбияләүдә әти кешенең роле җитмәүне билгеләп үтте.

– Бүгенге көндә аларны гаиләгә акча алып кайтып бирү проблемасы гына борчый. Акча эшли, ашата-киендерә, шуның белән бетте китте. Бала тәрбияләргә вакыт юк, дип акланалар. Чынлыкта гаилә тәрбиясендә ата кешенең йогынтысы гаять зур, – ди ул.

Казан казые Абдулла хәзрәт Әдһәмов та, аның сүзен куәтләп, гаиләнең терәге ир-ат булуын билгеләп үтте.

– Гаиләдә баш кеше – ир-ат, мин монда командир дип гайрәтләнеп йөри беләләр, ә үз өсләренә җаваплылык аласылары килми. Әтинең балага калдырган иң зур мирасы – яхшы тәрбия. Без имамнар җомга вәгазьләрендә халыкка шуны төшендерергә тиешбез. Дәүләт диннән аерылган дибез, әмма җәмгыять диннән аерылмаган. Гаиләдәге проблемаларны ялгыз гына чишеп булмый, моның өчен фән дә, төрле җәмгать оешмалары, полиция хезмәткәрләре дә, дин белгечләре дә бергәләшеп эшләргә тиеш. «Кешеләр үз хәлләрен үзләре үзгәртмичә торып, Аллаһы Тәгалә аларның хәлләрен үзгәртми», – дип тәмамлады ул сүзен.

ТАТАРСТАННЫКЫН САЙЛА

Җаны теләгән – елан ите ашаган

«Декабрь аенда «Казан» агросәнәгать паркына 400 000 кеше килде», – дип хәбәр итә паркның матбугат үзәге. Саннарның елдан-ел артуы нигезсез түгел, биредә сатып алучыларны ай саен диярлек яңалыклар көтә.

Узган ел ахырында Агросәнәгать паркында күпләр өчен ят булган продукция тәкъдим итүче ике яңа бүлек ачылган. Хәзерге гурманнарга кыргый кабан дуңгызы, кыр кәҗәсе, поши, кондыз, суер һәм хәтта аю итеннән казылыкны әллә кайдан эзләп йөрисе юк. Казанда кыргый хайван итеннән казылыкларның мондый бай ассортиментын, Агросәнәгать паркыннан кала, беркайдан да табып булмый. Шулай ук А залында «Балык-Маркет» бүлеге дә ачылган, ул Агросәнәгать паркына килүчеләргә диңгез һәм Төньяк Байкал балыкларының бай ассортиментын тәкъдим итә. Балыклар турында һәм аларның бәясен яхшы белүчеләр өчен хәбәр итәбез, биредә омуль, чир, муксун сатуда һәрвакыт бар. Шунысын да әйтергә кирәк, тере карп яки мәрсин (осетр) балыгын, яхшы сыйфатлы кызыл уылдык һәм башка деликатесларны да очсызрак бәядән сатып алырга була.

Җаны теләгән – елан ите ашаган, диләр. Сүз дә юк, кемнәр өчендер ярып пешерелгән бәрәңге әллә нинди ят ризыклардан да өстенрәк. Андыйларны да куандырабыз, биредә Арча бәрәңгесен 15 сумнан гына сатып алып була. Бәрәңге янына кетердәп торган тозлы кыяр дисез икән, анысының килосы – 80 сум.

Агросәнәгать паркында эшләп килүче «Казаночка» кафесы да яңа елдан ризыкларның ассортиментын тагын да баеткан. Тотрыклы түбән бәяләр, сыйфатлы ризык кулланучыларның санын көннән-көн арттыра. Ай саен кафенең баш пешекчесе кунакларына берничә яңа ризык тәкъдим итә. Мисал өчен, гыйнварда 5 оригиналь позиция кулланылышка кергән инде, бу – «Сыер ите белән яшелчәләр ашы – гуляш» (порция өчен 90 сум), «Гөмбә белән щи» (порция өчен 45 сум), «Гөмбә белән фетучини» (порция өчен 110 сум), «Яшелчәләрдән сотe» (порция өчен 50 сум), «Каймаклы крем белән бисквитлы пирог» (порция өчен 45 сум).

Агросәнәгать паркының сайтында күзәтеп барсагыз, бөтен акцияләр турында иң беренчеләрдән булып белеп барачаксыз. Тиен сумны саклый, диләр. Аның өстенә ризык сыйфатлы да булса, бигрәк тә яхшы.

vk.com

Язмада «Казан» агросәнәгать паркының матбугат үзәгеннән алынган материаллар кулланылды.

Ул тыйнак кеше иде

Күренекле режиссер, артист, рәссам, республиканың халык артисты һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Празат Исәнбәт – милли театр сәнгатенең традицияләрен саклап, аның үсешенә үзеннән зур өлеш керткән шәхесләрнең берсе. Празат аганың театр өлкәсендәге эшчәнлеген бөтен тулылыгы белән яктырту түгел ниятем. Аның белән азмы-күпме аралашкан кеше буларак, кызыклы бер хатирәне күп еллар күңелемдә саклап килдем.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

1957 ел. Урал төбәгендә уздырылган һәвәскәрләр конкурсында (хәзерге Екатеринбург) татар биюе башкарып җиңеп чыккан өчен, миңа Ташкент хореография училищесына юллама бирделәр. Ләкин соңарып барганлыктан, кире Оренбургка кайтырга җыенып йөргәндә, урамда Камал театрының афишаларын күрдем. Үзбәк Хәмзә театрына барсам, бәхетемә, беренче очрашкан кешем Камал театрының баш режиссеры Ширияздан Сарымсаков булды. Аңа, кыяр-кыймас кына, артист булырга теләгем барлыгын һәм Ташкентка килеп чыгуымның сәбәбен сөйләп бирдем. Шул ук көнне мине Хәмзә театрының сәхнәсенә чыгарып җырлатып, биетеп, этюдлар эшләтеп, сәләтемне сынадылар һәм театрга алырга булдылар.

Мин – Оренбург ягының караңгы бер авылында туып-үскән малай. Киләчәк тормышымда татар милли театры, музыка сәнгатенең бөек шәхесләре белән аралашып, дуслашып, хәтта татар театры сәхнәсендә атаклы артистлар белән янәшә торып уйнармын дип төшемә дә кермәде. Ә тормыш юлым, иҗат адымнарым, бәхетемә, шулай башланды.

Башта спектакльләрдәге күмәк күренешләрдә уйнадым. Соңрак кечкенә генә рольләр бирделәр. Хәтта атаклы сәхнә йолдызы Фатыйма Ильскаяның бенефисына багышланган Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры»нда миңа Каюм ролен уйнарга насыйп булды. Ул рольне күренекле җырчыбыз Зифа Басыйрова уйнаган. Соңыннан аның белән күп еллар бергә миңа Татар дәүләт филармониясендә эшләргә туры килде.

1958 елда Камал театрында Мирсәй Әмирнең «Гөлшаян» комедиясе куелды. Гөлшаян ролен – Рәшидә Җиһаншина, төп герой Әхмәтне – Празат ага Исәнбәт, ә мин Ибекәй исемле малай ролен уйнадым. Шул җәйдә без Арча ягына Тукай-Кырлайга килдек. Җәйнең гаҗәеп матур бер мизгеле иде. Празат аганың ирексездән күңелен биләп алган табигать аңа кулына каләмен алырга мәҗбүр иткәндер. «Әйдә энекәш, тыныч кына утырып тор», – дип, минем йөземә карап, нидер ясый башлады. Бераз вакыт узгач кына: «Үзеңә соңрак күрсәтермен әле», – дип, дәфтәрен җыеп куйды. Театрдан киткәч тә, Празат ага белән күрешеп, очрашып йөрдек, әмма ул минем портретым турында бернинди дә сүз кузгатмады.

Бервакыт «Шәһри Казан» газетасында Празат ага турындагы язма белән минем портретым басылган иде. 46 елдан соң үземнең яшь чагымда ясалган портретымны күрү үзе бер могҗиза түгелмени?

Шул ук вакытларда (2004 елда) Татарстан Милли музеенда режиссер, рәссам, республиканың халык артисты һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Празат Исәнбәтнең күргәзмәсе ачылды. Анда аның 40тан артык эше тәкъдим ителгән иде. Монда рәссамның Камал театрында эшләү чорында куелган спектакльләргә ясалган декорация эскизлары һәм күренекле мәдәният-сәнгать эшлеклеләренең портретлары һәм дусларча иҗат ителгән шаржлары урын алды. Шулар арасында минем дә «Артист улы» дип аталган портретым куелган. Аның күчермәсе үземдә саклана. Хәзерге көндә Празат Исәнбәтнең рәссам буларак тупланган эшләре Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының музеенда саклана.

Әйе, театрда эшләгәндә дә аңа яшьлегендә сайлаган һөнәре тынгылык бирмәгән, әдәбият, сәнгать әһелләренә багышланган шаржлары, акварель буяу белән ясалган рәсемнәре шул турыда сөйли. (Ул Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлый.)

Әлбәттә, бу рәсемнәрне Празат аганың хатыны Әлфия ханымның күз карасыдай кадерләп саклавы киләчәк өчен кирәк булган. Дөрестән дә, Празат ага үзе дә, сизмәстән, зур театр тарихын сәнгатьчә туплаган. Мәхәббәт җимешләре булып Празат аганың улы Ренатка да рәсем ясау һөнәре әтисеннән күчкән, күрәсең. Ул Камал театрында рәссам булып эшли.

Празат ага тыйнак кеше буларак, үзе исән чакта ул иҗат эшләре турында бер дә әйтергә кыймаган, бу хакта хәтта театр кешеләре дә белмәгән. Аның рәссам буларак тупланган эшләре беренче тапкыр хатыны Әлфия ханымның тырышлыгы аркасында Актерлар йортында күрсәтелә.

Бу шәхескә Ходай сәләтне өеп биргән. Празат ага – халык күңелен үзенең фидакарь хезмәте белән яулаган шәхес, нәкъ менә аның кебек милләтнең асыллары җәмгыятебезнең яшәешен һәм үсешен билгели, халыкның тарихын баета.

«Атаклы галим, шагыйрь, мәшһүр драматург, татар әдәбиятыбызның, татар сәнгатенең алып каһарманы Нәкый ага тәрбиясен алган актер һәм режиссер Празат Исәнбәтнең хезмәте тарихта җуелмаслык эз калдырды», – дип бәяли Празат аганың иҗатын Рабит Батулла.

Празат Исәнбәт әле дә булса табигате, фигыле белән халкыбызның, аның белән аралашып яшәгән дуслары, сәхнәдәшләре күңелендә саклана.

Раил СӘЙФУЛЛИН,
Татарстанның атказанган укытучысы.

КҮРГӘЗМӘ ЗАЛЛАРЫНДА

«Эрмитаж-Казан» үзәгендә Казан халкы һәм кунакларга яңартылган «Петербург модерны. 1890-1910 еллар. Стиль һәм совет модасы» экспозициясен тәкъдим иттеләр. Күргәзмәдә 28 экспонат алмаштырылган, алар арасында XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башында төшерелгән фотосурәтләр һәм француз рәссамы Поль Сезарь Эллёның график эшләре бар. Экспонатларны алмаштыру саклану шартлары белән бәйле. Чөнки ут тәэсире астында кәгазьләр структурасын югалта, шуңа да алар күргәзмәдә өч айдан артык була алмый.

Экспозициядә патшалар һәм югары дәрәҗә Россия аксөякләре өчен иң яхшы мода йортлары тарафыннан эшләнгән модерн чоры костюмнары һәм аксессуарлары, Дәүләт Эрмитажының «Петербург модерны» күргәзмәсендәге интерьер предметлары да урын алган.

* * *

«Хәзинә» милли сәнгать галереясында Антон Леухин һәм Надия Миңнеәхмәтованың «Урман» дип аталган күргәзмәсе ачылды. Рәссамнар икесе дә Татарстанда туып-үскән. Хәзерге вакытта Санкт-Петербургта яшәп иҗат итәләр. Штиглиц исемендәге Сәнгать-сәнәгать академиясен тәмамлаганнар. Алар күргәзмә һәм симпозиумнарда, шул исәптән халыкара чараларда еш катнаша. Күргәзмә 20 февральгә кадәр дәвам итәчәк.

* * *

Болгар цивилизациясе музееның күргәзмә мәйданчыгында «Борынгы Болгар шәһәре» дигән Татарстан рәссамнары эшләреннән торган күргәзмә ачылды. Анда рәссамнар Равил Заһидуллинның, Булат Гильвановның һ.б. картиналарын күрергә була.

Борынгы Болгар шәһәре күп еллар буе Россия һәм чит илләрнең танылган рәссамнары игътибарын үзенә җәлеп иткән. Бу традиция безнең көннәрдә дә дәвам итә. Тамашачылар игътибарына тәкъдим ителгән эшләр арасында III төбәкара Арт-экспедиция вакытында иҗат иткән картиналар да бар.

Күргәзмә белән февраль урталарына кадәр танышырга була.

«Көмеш туебызга да килеп җиткәнбез»

Әгәр берәр артист сәхнәдән югалып торса, тамашачы аны юксына башлый. Шактый еллар эстрадада юмор остасы булып эшләгән Илсур Мортаза да соңгы вакытта Казан сәхнәләрендә күренми башлады һәм бу сәбәпсез дә түгел: бүгенге көндә Буа татар дәүләт драма театрында эшли ул.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

– Илсур, ни өчен эстрададан китәргә булдың? Буа театры белән элемтәләр ничек башланды?

– Мин Раил Садриев белән балачактан таныш. Ул: «Әйдә, бездә эшләп карамыйсыңмы?» – дигәч, аңа каршы килмәдем. Театр ул – үзенчәлекле дөнья. Минем күптәннән спектакльдә уйнап карыйсым килә иде. Ниһаять, ул хыял тормышка ашты. Шулай да эстраданы ташлап бетерергә җыенмыйм. Алар бер-берсенә комачауламый.

– «Килә ява, килә ява» спектакле Камал театры сәхнәсендә дә барган иде. Сездә куелганында Фәрит Бикчәнтәев үзенә сантехник Шәйхулла ролен биргән. Аның белән эшләү ничек булды?

– Камал театрында ул рольне Рәшит Шамкай, Әсхәт Хисмәт кебек танылган артистлар уйнаган. Фәрит белән эшләү зур тәҗрибә бирде. Ул күрсәткәнне, аның артыннан кабатлау җиңел түгел. Кызыклы гына образ килеп чыкты.

– Син сәхнәдә юмор жанрында эшләдең. Эстрададан соң театр бик җитди булып тоелмыймы?

– Әйе, эстрадада кеше көлдерү өчен нәрсә генә эшләмисең. Ә театрда артык сүз кирәкми. Анда килеп туган хәлдән мимика, хәрәкәтләр ярдәмендә чыгасың. Эстрадада тамашачы белән турыдан-туры элемтә була, ә театрда залга карасаң, образның сыйфаты югала.

– Элекке гадәт белән тамашачы хәзер дә елмаеп каршы аладыр әле үзеңне.

– Чыннан да, сәхнәгә чыгуга, тамашачы көлеп җибәрә. Юмор көтә. Спектакльдә юмор тирәнрәк. Эстрадада анекдотка күчеп барабыз бит инде.

– Театрда эшли башлагач, эстрадага карашың үзгәрмәдеме?

– Мин шундый фикергә килдем, бүген эстрадада теләсә кем артист булып эшли ала. Кемнеңдер әтисе, абыйсы бай. Бүгенге көндә эстрадада акча эшләү җиңел, дип уйлыйлар. Зәвык юк, теләсә кем көй яза, теләсә кем аранжировка ясый. Татар җыр сәнгатенең үз йөзе калмады. Мин бервакыт охшаш җырларга попуррилар да башкарган идем. Әмма аларга колак салучы гына булмады. Хәзер үз йөзе булган җырчылар аз, тембр буенча кайберләре бер-берсеннән аерылмый.

– Бүген эстраданы үзгәртергә мөмкинме?

– Идеология булмаганда, яшь буынны тәрбияләү мөмкин түгел. Совет чорында идеология бар иде. Хәзер мәгънәсез җырлар, башкаручылар шулкадәр күп. Берәр дәүләт программасы булганда гына эстраданы тәртипкә салырга мөмкин.

– Хатының Мәүлидә дә сәхнә кешесе. Үзе җырлар язып аларны башкарса да, соңгы вакытта күзгә чалынмый. Улыгыз Робертның да матур гына җырлавын беләбез. Киленегез Алия дә биюче. Читтән кеше эзләмичә, үзегез дә концерт программасы әзерли аласыз кебек...

– Безнең бергә яши башлавыбызга тиздән 25 ел була. Көмеш туебызга да килеп җиткәнбез. Шул уңайдан март аенда Тинчурин театрында үзебезнең концертны оештырырга ниятлибез. «Көмеш туй» дигән җыр да яздырырга исәп.

– Чирек гасыр дәвамында син ир кеше өчен кирәк булган нәрсәләрнең барысын да эшләргә өлгердең булса кирәк.

– Аллага шөкер, агач утырттым, бала үстердем, йорт салдым.

– Син бит әле дизайнер, рәссам да. Йорт салганда ул сәләтеңне кулланырга да җай чыккандыр.

– Әйе, йортыбызны үз проектым буенча салдым. Күп өлешен Мәүлидә белән икәү төзедек. Әмма ясаган картиналарым гына үземдә сакланмый. Дусларга бүләккә китә бара.

– Берничә ай элек оныгың туу үзеңә йогынты ясадымы?

– Мин бераз дуамалрак. Хәзер холкымны үзгәртергә туры килә. Бергә яшәгәч, балаларга үрнәк булырга кирәк. Гастрольләрдән дә оныгыбыз Оливияне сагынып кайтам.

«Сандугач»лар кыш дип тормый

Түбән өлкәсендәге Ялутор шәһәрендә эшләп килүче «Сандугач» ансамбле җитәкчесе Зөһрә Кожевникова үзенең күптәнге хыялын тормышка ашырган. Ансамбльгә йөрүчеләрне Түбән өлкәсенең милләтләр эшләре буенча комитет булышлыгы белән башкалабызга алып килгән.

Марсель Мәсәгутов фотосы

Коллективта барысы 15 хатын-кыз. Зөһрә ханым үзе башта мәгариф өлкәсендә хезмәт куйган. Соңгы 15 ел дәвамында әлеге ансамбльне җитәкли.

– Безнең барыбызның яшен бергә кушсак, 1043 яшькә җыела, ә уртача яшебез 73ләр тирәсе. Репертуарыбызда 80гә якын җыр бар. Бигрәк тә халык һәм эстрада җырларын, бәетләр, мөнәҗәтләрне яратып башкарабыз. «Төйдергечләр» дигән фольклор уены да күрсәтәбез, – ди җитәкче.

Ансамбль шактый гына фестивальләрдә катнашып, лауреат булган. Тирә-юньдә үткәрелә торган чараларның берсе дә алар катнашыннан башка узмый. Былтыр «Сандугач» ансамбленең 25 еллыгын да үткәргәннәр. Надежда Мальцева – 20 ел буе ансамбльнең алыштыргысыз баянчысы. Милләте буенча рус кешесе булса да, татар җырларын җырлый. Коллективта һәркайсының тавышы үзенчәлекле. Нурзия Калиева белеме буенча медицина хезмәткәре. Ул ансамбльгә 15 ел йөри. Ата-бабаларыннан мирас булып калган борынгы җырларны өйрәнү теләге тартып китергән аны биргә.

Кунаклар Бөтендөнья татар конгрессында да булдылар.

– Без сезнең ансамбльне ишетеп тә, күреп тә беләбез. Сез телебезне, мәдәниятебезне саклауда зур өлеш кертәсез. Сездәге көчле энергетика күренеп тора, – диде Бөтендөнья татар конгрессы рәисе урынбасары Данис Шакиров.

«Ак калфак» оешмасы җитәкчесе Кадрия Идрисова коллективка, халыкка рухи азык өләшкәннәре өчен, рәхмәтләрен җиткерде.

– Сезнең тавышыгыз гаҗәеп, чын сандугачларныкы сыман, исемегезгә туры килә. Киемнәрегез дә милли, зәвыклы итеп тегелгән. Безгә элекке киемнәрне кире кайтарырга кирәк, – дигән теләкләрен дә ирештерде Кадрия ханым.

Кунаклар үзләренең репертуарларындагы кайбер җырларын да башкардылар.

Кунаклар кичә Арча районында Тукай эзләре буйлап сәяхәт иттеләр һәм концерт куйдылар. Бүген Казанның истәлекле урыннарында булачаклар.

Люция ГАЛИМҖАНОВА.

Камаллылар тагын бер атнага китә

14-21 февральдә Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләренә гастрольләр белән китә. Анда биш спектакль алып баралар. Спектакльләр «Энергетик» мәдәният сараенда һәм Түбән Кама Халыклар иҗаты йортында күрсәтеләчәк. Тамашачы Зөлфәт Хәкимнең «Бармы ришвәттән дәва?», Туфан Миңнуллинның «Диләфрүз», Кәрим Тинчуринның «Җилкәнсезләр», Илгиз Зәйниннең «Көтәм сине» дигән әсәрләрен тәкдим итәчәк.

Эстрада җырчылары джаз җырлый

7 февральдә Татар дәүләт филармониясе сәхнәсендә татар эстрадасы җырчылары чыгыш ясый. Анда Татарстан Республикасы Филармония джаз оркестрына кушылып Рөстәм Яхин, Резеда Ахиярова, Сәйдә Вәлиди, Эльмир Низамов, Эльмира Галимова, Сәгыйт Хәбибуллин һәм башка композиторлар иҗат иткән җырлар, инструменталь әсәрләр башкарылачак. Айдар Сөләйманов, Айгөл Бариева, Лидия Әхмәтова, Алсу һәм Азат Фазлыевлар, Эльнар Сабирҗанов һ.б. җырчылар катнашачак.

Әлеге проектның җитәкчесе – Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Лидия Әхмәтова.

«Тормышымда начар кешеләр очрамады»

Бүген без зарланырга тәмам остарып җиттек: замананы сүгәбез, артып торучы бәяләр теңкәгә тия, кар баскан юллар, транспортның озак йөрүе эчне пошыра, картларга яшьләр кыланмышы ошамый, яшьләрнең ачуын өлкәннәр чыгара... Тыңлап торсаң, бүген дөньясында язмышына риза булып яшәгән бер генә кеше дә калмаган, диярсең. Журналист икәнеңне белгәч, ул зарлар тагын да арта әле. Шуңа күрә дә 80 яшьлек гомеренең һәр көненә риза булып, Ходайга рәхмәт укып яшәүче Флюра апа Кашапова белән танышкач, рәхәт булып китте. Ә бит язмыш дигәннәре аны да гел бишектә генә тирбәтмәгән.

«Үтте дә китте гомерем,
Үткәнен дә күрмәдем,
Үтмә диеп, китмә диеп,
Взятка да бирмәдем», – дип җырлап каршы алуыннан ук мин аның җор телле, яшь күңелле икәнен төшендем. Таратып бәйләгән ап-ак яулыгының, чигүле матур күлмәгенең үзенә ничек килешле булуын әйтмим дә инде. Хәтеренә дә күз тимәсен. Үзенең 80 еллык гомер йомгагын күз алдымда бик тиз сүтеп чорнады Флюра апа.

– Без – сугыш чоры балалары. Әтием яу кырына киткәндә, миңа – дүрт, бер энемә ике яшь, ә иң кечкенәсе күкрәк баласы гына булган. Туган ягым Дөбъяз төбәге булса да, әтием, миңа бер яшь тулганчы ук, гаиләсен Казанга алып киткән. Бәхетле булып, шунда озын гомер итәргә җыенган булган... Тик әтием сугышта һәлак була. Шушы кайгылы хәбәрне китергән кара кәгазь әниемне – тол, без өч баланы ятим итте. Әниебез бик акыллы һәм гадел иде. Без балаларын хезмәтне яратырга, тырыш булырга өйрәтте. Үзе дә кул эшләренә: тегәргә-чигәргә бик оста иде. Олы кыз булганлыктан, миңа кул арасына иртә кирәргә туры килде. Энекәшләрнең күлмәк-ыштаннарын ямап, тегәргә өйрәндем, һәм ул минем гомерлек һөнәрем булды, – ди Флюра апа.

Үзенә диган туй күлмәген дә үзе тегеп кия ул. Әллә шуның сере-тылсымы, әллә инде холкының нигезендә сабырлык яткангга, авызы тулы кан булса да, кеше алдында төкерми. Каенсеңелле-каенэнеле зур дини гаиләгә килен булып төшкән җирендә таш була ул. Үзен дә, ирен дә бәхетле итеп яшәтергә тырышып, гомеренең 58 ел ярымы үткән дә киткән.

– Ул әйткәнгә мин риза булдым, мин әйткәнгә ул каршы килмәде. Эчми-тартмый, акча эшли, балаларын ярата торган ирнең нинди гаебен табасың ди тагын. Мин аны югалтудан, балаларымны ятим итүдән куркып яшәдем. Үзем дә әтисез үстем, моның ни икәнен беләм, – диде Флюра апа, елмаеп.

Югалтудан курку да сәбәпсез булмый. 44е генә тулган типсә тимер өзәрлек Мөниренә, җир җимертеп эшләп йөргәндә, инсульт була.

– Хастаханәдән шалтыратып хәбәр иткәч, күз алларым караңгыланды. Килеп керсәм, коридорда ята. Янында ярдәм итүче дә күренми. Кыюлык кайдан килгәндер, ординатура ишеген ачып кердем дә: «Бу кеше – ике бала атасы, үз эшенең остасы. Алай-болай булса, җавап бирәчәксез!» дидем, – дип искә ала ул чакларны Флюра апа.

Ирен сабый баланы караган дай тәрбияләве юкка китми. Көчле мәхәббәт каршында инсульт җиңелә, әҗәл чигенә. Дүрт ел буе бер эш тә эшләтмичә, китап кына укытып утырта ул ирен. Аның каравы, хәзер 90ны ваклаган Мөнир абзый карын да күри, бакчасын да казый. «Хәрәкәттә – бәрәкәт» дип, мин килгәндә дә ишегалдын кичәге буран өйгән кардан ялт иттереп чистартып куйган иде.

Үзен – тол, балаларын ятим калдырмаган өчен, язмышына, Аллаһыга рәхмәтле Флюра апа. Лаеклы ялга чыккач та башта мәчеттә, аннары «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә гыйлемен арттыра. Атаклы Рәшидә абыстай Исхакыйның яраткан шәкерте була ул. Гомер буе күршедә бер урамда яшиләр. Моның белән дә горурлана Флюра апа. Аннары үзе дә остазбикә мөгаллимә булып, «Мәрҗани» мәчетендә шәкертләр укыта башлый. Әниләренә ияреп килгән балаларга да дин сабагы бирә. Үзе дә ике бала үстергән ана буларак, тәрбия серләрен күп белә. Хәзер инде шәкертләренең төгәл генә санын да белми. 500ләп булыр, ди. Ә менә шәкертләре үзләренә дини белем-тәрбия биргән остазларын онытмыйлар.

Өлкәннәрнең яшьләргә карата фикере бик уңай булмаганны белгәнгә, Флюра ападан да: «Замана яшьләренә мөнәсәбәтегез ничегрәк?» – дип сорадым, тел төбен чамаларга теләп.

– Бик әйбәт, кызым, оныкларымнан беләм. Бер оныгым Гөлнара бүген элек үзе укыган гимназиядә укыта. Әнисе юлыннан китте. Калган өч оныгыма да телтеш тидерә торган түгел. Укыйлар да, солдатта да булдылар. Яшьләрнең әйбәтлеген күрше балаларыннан да күрәм. Алар да бик тәртиплеләр. Кешенең нинди икәне исәнләшүеннән күренә. Начарлары элек тә булган инде аның, ашлык кибәксез булмый, диләр бит. Миңа гомеремдә дә начар кешеләр очрамады, Аллага шөкер, – ди ул.

Озын бәрәкәтле тормыш юлы узып, бүген бер үкенүләрсез көн итеп ятучы, пар канатлары белән иман күгендә тирбәлүче Флюра апа Кашаповалар өеннән мин бер хакыйкатькә инанып чыктым. Зар – зарланган саен арта, карасын күргән саен, дөнья караңгылана, кояш сүрәнләнә икән ул. Ә инде булганына риза булып, югын бар итәргә тырышып, шөкрана кылып хәләл яшәгәндә, гомер мәгънәле дә, ямьле дә, бәрәкәтле дә.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

ПОЧТАДАН

Менә килә дия-дия көтәбез

Көн туса, тукталышка йөгерәбез. Минуты-сәгате кадерле шул иртәнге якта. Эшкә соңга каласы килми. Сәгатькә карый-карый чабасың. Эштән чыкканда да, тизрәк өйгә кайтып керәсе килә. Казанның күп кенә тукталышларында транспортның кайчан киләчәген күрсәтә торган таблолар эшли. Бик тә уңайлы. Бу арада көннәр бигрәк салкын тора. Шуңа да, тышта суык булса да, автобусның ничә минуттан килеп җитәсен күрсәтә торган таблолар күңелне җылыта. Бер аяктан икенчесенә сикерә-сикерә, менә килә, менә килә дип көтәсең. Тик бөтен тукталышларда да юк бит шушы. Үзебезнең Ваһапов тукталышында юлның ике ягында да юк алар. Ә кайбер тукталыштагы таблолар бөтенләй дә эшләми. Нишләп аларны карап торучы юк? Уңайлы шәһәр дияргә яратабыз. Бу яктан караш бөтен тукталышларга да тигез булсын иде.

***Лилия* МОХТАРОВА,**
Казан.

Укыганнар да алганнар

Менә икенче ел инде мин «Шәһри Казан» газетасын алдырам. Бик ошаттым, быел чордашларыма, авылдашларыма да яздырдым. Файдалы, мәгълүматлы газета. Халыкны кызыксындырган темаларга язасыз. Без, өлкәннәр, сәламәтлек турындагы язмаларны яратып укыйбыз. Исән-сау булып, озаграк яшисе килә. Әле менә быелның беренче санында карабодай оның файдасы, аны кефир белән эчү турында язма басылган иде. Укып чыктым да кибеткә киттем. Алып кайттым да язылганча эшләп карадым. Тәмле дә, файдалы да тоелды. Аннары бу турыда таныш-белешләргә, туганнарга да сөйләдем. Аларның да озак яшәүләрен телим бит инде. Шул кибеткә барып, болар да карабодай онын алдылар. Берничә көн үткәч, тагын алыйм дип барсам, беткән. Сатучылардан сораган идем, «Бик тиз алып бетерделәр, моңарчы сораучы да юк иде, ни булгандыр?» – дип аптырашып торалар. Ә мин сәбәбен беләм, халык «Шәһри Казан»ны укый, димәк.

Миңнислам ВӘЛИЕВ,
Казан.

Яшәсен авылдашларым!

Кышкы каникулдан соң минем әле төзелеп тә бетмәгән йортымда янгын чыкты. Узган ел газ кертергә җитешмәдем, үзем ясаган мич белән утын ягып кына өйне җылыта идем. Тиешле шартлары булмагач, авыру әниемне, кыш чыгарга дип, күрше Зур Сукаеш авылындагы туганнарыбызның буш калган йортына урнаштырып тордым. Үземнең саксызлык инде, утынны артыграк тутырып, кичкырын эштән соң, әни янына барып кайтырга дип кенә чыгып киткән идем.

Кичке тугызынчы яртыда күршебез Рамил Ихсанов тәрәзә аша өй эчендәге ялкынны күреп алып, ашыгыч төстә авылдашларны ярдәмгә чакырган. Тиз арада 50ләп кеше җыелып өлгергән. Савымчы Галина Мелихова: «Янгын сүндерергә барыбыз да кар көри торган көрәкләр белән килдек», – ди. Авылда су юк шул безнең, югалып калмаганнар, кар белән сүндергәннәр, рәхмәт яугырлары. Район үзәге бездән 32 чакрым, янгын сүндерүчеләр тиз генә килеп җитәрлек түгел.

Авылдашларым яшәсен, аларга нинди генә рәхмәтләр әйтсәм дә, аз булыр. Насыйбуллиннар, Сафиуллиннар, Хөрмәкәевләр, Гәрәевләр, Хәсәеновләр, Дәүләтгәрәевләр гаиләләре һәм башка бик күпләр күрсәткән шәфкатьлеккә бик сөендем. Кайгы-хәсрәтләр күп күргән кеше буларак, күңелем тулды...

Авылны саклап калу турында законнар күп чыгарабыз дип сөйлиләр телевизордан. Закон чыгару белән генә түгел шул. Урта мәктәбе дә булган безнең зур авыллар да авырлык белән генә көн күрә. Уйламаганда минем өемдә янгыны да чыгып куйды, әнә күршем Альбертның шушы арада 20 куянын хуҗасыз этләр ашап киткән.

Ирек ГӘРӘЕВ,
Азнакай районы,
Урсай авылы.

БАШКОРТСТАНДА ЯШӘҮЧЕ КҮРЕНЕКЛЕ ТАТАР ШАГЫЙРЕ САЛАВАТ РӘХМӘТУЛЛАГА – 75 ЯШЬ

Тукай – Уфада

...1912 елның апрель аенда Габдулла Тукай Уфага килә һәм Мәҗит Гафури белән очраша. Мәҗит Гафури, пальтосын сатып, Тукайны кунак итә.

(Рәсми чыганаклардан)

Узганнарда – тарих, «узганнар»га
Йөз еллап кына булса да...
Шул йөз еллап вакыт аръягыннан
Хәбәр килә: «Тукай – Уфада!..»

Хат та салмый алдан, «Башкорт дуслар
Тукайны чит күрмәс, – дигәндер. –
Гафурига фельетоннар яздым,
Ул хәтта кул бирмәс!..» – дигәндер...

Ә Гафури... «Кайда туктар ул?!» – дип,
Әллә ниләр юрый Гафури.
Һәр тарафта сорый, иң кыйммәтле
Номерларны урый Гафури...

«Кайда? Бәлки...
башкорт дуслардадыр...» –
Чыгалмый ул уйлар очына...
...Туберкулез Тукай
«Сабах» кибетендә, әрҗәләрдән
Сәке ясап, унбиш кич куна...
Бу елны һич онытырга түгел,
Онытырга түгел бу айны:
«Кышка кадәр рәте табылыр», – дип,
Бөек Гафури, пальтосын сатып,
Кунак итә сырхау Тукайны...

...Егерме җидедә үләр Тукай,
Гафури да
Илле дүрте тулгач үләчәк...
Бөек Тукай, Бөек Гафуриның
Бөеклеген бөек Русиябез
Чорлар узгач кына беләчәк...

Чорлар узган шагыйрь язмышлары
Һаман әллә ниләр уйларлык.
Эх...
Казаннардан шагыйрь дуслар килсә,
Пәлтәм дә юк – сатып сыйларлык...

Думада

...Еллар – Думада эш кайный
(Тагын кайда кайнасын?!):
Дума кадәр Дума булгач,
Эшләр мөһим: аңла син.

Иң мөһимнәрдән мөһиме –
Халыкка арт бормаска:
Аңа... хәмер каптырмаска!
Тәмәке тарттырмаска!..

Көрәшчеләр

Хәйләләрсез,
Саф татарча көрәш –
Көрәшләрнең сыйфат билгесе.
Бер кысыла мәйдан... бер языла:
Кемдә калыр батыр сөлгесе?..

Егетләрнең сөлек кебекләрен
Берәм-берәм батыр егачак...
Батырдан да батыр пәһлеванга
Иң соңыннан
Садыйк чыгачак!..

Һәм ул чыккан! –
Беркем күрмәгәндер
Көрәшченең аңа тиңдәшен:
Бер ыһ иткән дә ул, җирдән аерып,
Башы аша чөйгән көндәшен!..

...Картәтием чалымнары, диләр,
Йөрешемдә...
Холкым...
Буйларда...
Күңелкаем
Җырга-моңга тулы.
Көрәшмәдем Сабантуйларда...

Телдән телгә, чордан чорга күчкән
Картәтием даны зур, беләм!
Сабантуйларда тик көрәшмәдем
Мин...
Бәйгегә кердем... җыр белән!

Хәйләләрсез,
Саф татарча микән
Бәйгеләрнең сыйфат билгесе?..
Эх...
Аяк чалган мөтәшагыйрьләрнең
Кулларында... шагыйрь сөлгесе...

Тамырларда –
җиңүчеләр каны! –
Мең ялганны бер хак егачак.
Бер кысылыр йөрәк, бер языла.
Иң соңыннан...
Шагыйрь чыгачак!..

Песи

Урманда адаштырсаң да,
Сагынып өйгә кайтыр.
Кадер бетсә дә,
Туган җир
Барыбер якын, матур!..

* * *

...Әрем орлыкларын коя
Минем туган нигезгә.
Таш кала – төяк безгә...

...Туган мәктәбем нигезең
Хәзер белүче дә юк,
Эзләп килүче дә юк...

...Каберлектә каберләр дә
Артканнан-арта икән:
Туган җир тарта икән...
Туган җирдә урыннар күп
Утырып уй уйлый торган...
Тәгәрәп елый торган...

Мәхәббәтсез дөньям –
карурман...

* * *

Гомер юлларымда үзем
Үземне сынап барам.
Ышаныч юк бу дөньяга!
Җанымны кыйнап барам.

...Бердәнберләремне упты –
Кыраудай сукты дөнья.
Әткәйне дә, әнкәйне дә
Гүрләргә тыкты дөнья.

Үземчә түгел, язмышны
Үзенчә үрде дөнья.
Өзелеп сөйгән ярны да
Ятларга бирде дөнья.

Ышанып кем күзләренә
Карыйм тагын да хәзер?! –
Җан атып йөргән дуслар да
Дошман ягында хәзер.

Юлымда җанымны хәзер
Учыма салып барам.
Нишлим?! Бу дөньяда хәзер
Берүзем калып барам.

* * *

Дөньяларым – сихри гөл бакчасы,
Шау чәчәктә чагы гөлләрнең.
Чәчәкләрнең чәчләреннән генә
Сыйпап искән чагы җилләрнең...

Түтәлләрдә үскән гөлләр сыман,
Тамыр – җирдә, җирдә – тирәгем.
Тормыш диңгезендә утрау сыман,
Атлантида сыман йөрәгем!

Күңелләрем җырга-моңга тулы
Вәгъдәң барда җанда-нигездә!
...Хыянәтең вулкан булып атса,
Гарасатлар кубар диңгездә...

Җир айкалып, күк чайкалып калыр...
Мәхәббәтсез дөньям – карурман.
Атлантида сыман югалырмын,
Атлантида сыман табылмам.

Шагыйрь юбилеен курчак театры башлады

Шагыйрьнең күңел дәрьясының тирәнлеген белер өчен аның шигырьләрен укырга яки иҗат кичәсендә булырга кирәк. Күптән түгел генә шундый кичә Татар дәүләт «Әкият» курчак театрында узды. Ул шагыйрь, Тукай премиясе лауреаты Зөлфәтнең тууына 70 ел тулуга багышланган иде. Олы шагыйрьнең юбилеен курчак театры коллективы башлавы тикмәгә генә түгел.

Үзе дә дүрт балага гомер биргән, «йөрәген былбыл чаккан»га моңлы, илһамга бай шагыйрь киләчәкнең балаларда икәнен яхшы аңлаган һәм иҗатының бер өлешен аларга да багышлаган.

Аның «Таңга – Чулпан, Айга – Зөһрә», Чыңгыз Айтматов әсәре буенча язылган «Гасырдан озын бу көн», «Җен кызы» һәм башка әсәрләре курчак театры сәхнәсеннән төшми озак уйналды.

Әлеге кичәдә театрның директоры Роза Яппарова һәм баш режиссеры Илдус Зиннуров бу спектакльләр өчен барлык нәни тамашачылар һәм өлкәннәр исеменнән Зөлфәт гаиләсенә рәхмәтен җиткерде. Бу

ихлас рәхмәт сүзләрен аның хатыны Фирая апа, балалары: Азамат, Илһам, Фазыл, Кадрия, аларның балалары – тугыз оньк һәм әлеге нәселнең аксакалы 100 яшьлек Салих ага да горурланып тыңладылар. Тамашачыларда да шундый хис иде. Мондый тирән фикерле, халкы белән бер уйда булган олуг шагыйрьле милләт үзе дә кечкенә була алмый. Шушы тойгыны күңелләрдә кабат яңартканы өчен, шагыйрь рухына дога кылып утырдык.

Зур тату гаилә бәйрәме шикелле бик җылы булды ул кичә. Анда шагыйрьнең чын дуслары, аның иҗатының фанатлары гына җыелган иде. Шагыйрь исеме кичәнең буеннан-буена былбыл белән янәшә яңгырады. Мөслим төбәгендә дөньяга килгән шагыйрь тамашачы күңеленә былбыллар телен аңлаучы булып кереп калды.

Кичәдә чыгыш ясаган Ркаил Зәйдулла, аның былбыл җанлы булуын искәртеп, истәлекләре белән уртаклашты.

Зөлфәтнең тууына 70 ел тулуга багышланган кичәләрнең бу беренчесе генә әле. Беренчесе, тик соңгысы түгел.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

«Бирде дөнья кирәкне, еламаска өйрәтте...»

Зөһрә САДЫЙКОВА

– Гомер буе авыру иремне карадым. Көнне төнгә ялгап эшләүләр, балаларны аякка бастыру, әти белән әни арасында бәргәләнү үз эшен эшләде, бик көчле стресс кичердем. Соңрак миндә күкрәк яман шеше ачыкланды. Тугыз ай буена яшәү белән үлем арасында көрәштем. Шул вакыт эчендә ирем бер генә тапкыр да хастаханәгә килеп карамады, хәлемне дә белмәде...

Карап торышка башкалардан әллә ни аерылып тормаган урта яшьләрдәге чибәр ханымның шулай дип ачылып китеп сөйләшүе гаҗәпкә калдырды. Якыннанрак аралаша башлагач, аның әле талантлы, укымышлы, үз эшендә даими эшләүче, укучыларын авызына гына каратып тота торган көчле педагог икәнлеге дә ачыкланды. Ә инде язмыш йомгагын сүтә башлагач, тормышны теше-тырнагы белән ябышып тартучы, тырыш, сабыр, үҗәт хатын икәнлегенә дә төшендем мин аның. Дөресен әйтим, яңа танышымның язмышын язу гына түгел, тыңлавы да авыр булды. Казанның бер мәктәбендә укытучы булып эшләүче ханым үзе турында язарга ризалык бирсә дә, исем-фамилиясен күрсәтмәүне, исемен Тәнзилә дип куюымны үтенде.

– Мин Югары Ослан районында туганмын, – дип сөйләде ул. – Мәктәбебез бик көчле иде, олимпиадаларда һәрвакыт алдынгы урыннар яулап килде. Ә менә гаиләбездә әти белән әни арасындагы мөнәсәбәтләр һәрвакыт авыр иде. Алар әле бергә, әле аерым яшәделәр. Әти укымышлы кеше булса да, эчәргә ярата иде. Шуңа күрә энем белән миңа бик авырга туры килде. Мәктәптә яхшы укыдым, чөнки ярдәм өмет итәр кешем юк, киләчәгем бары тик үземнең тырышлыгымнан гына торачагын белә идем. Институтта да белем алу миңа канәгатьлек китерә иде, төркемдәшләрем белән дә бик дус яшәдек. Бөтен чараларда катнашып килдем, төркемнең старостасы идем. 100 сум стипендия алып, энемә дә гел булышып тордым. Уку йортын кызыл дипломга тәмамлагач, миңа теләсә кайсы мәктәпкә эшкә бару хокукы бирелде, әмма бер кызыбыз Казанның иске мәктәбенә укытырга барудан баш тарткач, мин аның урынына алындым. Шуны әйтәсе килә, гомер буе профессиональ яктан камилләшергә тырыштым, география, биология фәннәрен укытам, медицина белән кызыксынам, «Ел укытучысы» бәйгесендә катнашып, дүртенче урынга лаек булдым. Вакытлы матбугатка фәнни мәкаләләр язам. Даими рәвештә конференцияләрдә катнаштым, укучыларым белән дә бик нык шөгыльләнә идем.



1983 елда кияүгә чыктым. Өйләнешкәч, ике ел бала алып кайтмадык. Мәктәптә дә укыттым, фән белән дә шөгыльләндем. Үз көчем белән уңышка ирешергә омтылдым. Минем эшне дә, укуны да, гаиләне дә бергә алып барасым килгән иде. Әмма табибләр, яки бала, яки аспирантура дип, сайлау алдында калдырды. Борчылулардан, лимфоденит авыруы булды. Онкология буенча исәпкә куйдылар. Ул вакытта барысы да уңышлы узды, терелеп беткәч, 1985 елда беренче баламны алып кайттым. Әмма нарасый гомеренең икенче тәүлегендә үпкә ялкынсынуыннан дөнья куйды. Ул вакытта мин бик зур югалту, тетрәнү кичердем. Бу авыр уйларга бирешергә теләмичә, вакытыннан алда эшкә чыктым. Шуннан соң 1986 елда – улыбыз Алексей, ике елдан соң кызыбыз Екатерина туды. Бу көннәрдә без бик бәхетле идек. Балаларымны бик яратам.

Безнең яшьлегебез бик авыр 90нчы елларга туры килде. Эш хакы аз, әйбер табып булмый. Шуңа күрә һәрвакыт мәктәптән тыш башка урыннарда да эшләдем. Эшенә дә чыдадык, алга таба да түзәргә әзер идек, әмма өйләнешүебезнең өченче елында ирем йөрәгенә авыр операция кичереп, инвалид булып калды. Әллә ничә тапкыр табиб пычагы астына керергә туры килде аңа. Аз булса да акча булыр дип, капчык-капчык чүпрәк-чапрак төяп, шуны танышларга сатып йөрүләр дә, кичен кибетләрдә администратор булып эшләүләр дә, салкыннарда базарда сату итүләр дә – берсе дә калмады. Кыскасы, 12 ел шундый коточкыч режимда яшәү үз эшен эшләде. Үт куыгындагы ташлар кузгалып, тиз арада операция ясатырга туры килде. Аннан соң әни авырып киткәч, аны үз янубызга алып килдем, әтигә инсульт булып, аны югалттык.

Мин үземне белә белгәннән бирле көрәшәм. Әйтерсең язмыш мине чыдамлылыкта сыный. Кабат аспирантурага керәм дип йөргән көннәрдә иремне тагын операциягә салдылар. Улымның гемоглобины бишкә кадәр төшеп, чактан гына үлемнән калды. Беребезнең дә каны туры килмәгәнлектән, тиз арада эритроцитар масса һәм кан плазмасы табарга кирәк иде. Ә бу бит 90 нчы еллар! Кан түгел, ашарга табу да кыен заманнар. Шуннан соң мин кан салу станциясенә бардым да, мөдирнең аягына егылып: «Бер баламны җир куенына салдым, икенчесен дә югалтасым килми. Зинһар, акылдан яздырмагыз мине!» – дидем. Рәхмәт төшкере, сүземне тыңлады. Шулай итеп без баланы коткарып калдык.

Балаларым югары уку йортларына түләүле бүлекләргә керде. Иремнең операцияләренә, балаларның укуларына акча җитмәгәнлектән, өч бүлмәле фатирны икелегә алыштырырга туры килде. Аның каравы, балалар икесе дә бик яхшы эшләрдә эшли хәзер. Яшәвемнең төп мәгънәсе булган ике оныгым бар. Үзем теләгәнчә һәм хыялланганча купшы туйлар уздырдык.

ТОРМЫШЫМНЫҢ ИҢ ЗУР ЯРАСЫ

Инде авырлыклар бераз чигенде. Рәхәтләнеп яшәргә дә яшәргә югыйсә... Әмма язмыш мине кабат сынады. 2014 елда миндә күкрәк яман шеше ачыкланды. Метастазалар күп иде. Катлаулы операция кичердем. Тугыз ай буена яшәү белән үлем арасында көрәштем. Бераз соңрак умыртка баганасында да метастазалар барлыгы ачыкланды. Тагын химия терапиясе, нурланыш... Ул көннәрдә ни кичергәнемне үзем генә беләм. Әмма иң аянычы – йөрәкне, бәгырьне актарып атып туктаусыз сызлатканы – гомер иткән иптәшемнең шул тугыз ай буена бер тапкыр да яныма килеп карамавы, хәлемне белмәве. Ул, кисәк кенә, минем белән бөтенләй аралашмас булды. Хастаханәдән чыгуга ук аерылышырга гариза яздым. Бүген бер түбә астында яшәсәк тә, аралашмыйбыз. Бик авыр көннәремдә дә аннан бер җылы сүз дә ишетмәдем, ягымлы караш та күрмәдем. Ярый әле балалар, хезмәттәшләр, дуслар, укучыларым хәлемне белешеп тордылар. Бу хәлләрдән акылдан шашарга да мөмкин идем бит! Алар миңа «теге дөнья»дан кире кайтырга ярдәм итте. Хастаханәдән: «Үлмим әле мин, кешеләргә кирәгем бар», – дип чыктым.

Хәзерге көндә Юля Юшкевич җитәкчелегендәге «Без бергә» төркемендә авыру балаларга булышабыз. Узган ел мине кызым чит илгә ял итәргә алып барды. Анда булып кайткач, күзләрем бераз ачылган төсле булды. Тормышның эш, көрәш өчен генә бирелмәвен аңладым. Якыннарым белән аралашам, җанга якын шөгылем бар – рәсемнәр, картиналар иҗат итәм, театрларга, концертларга йөрергә тырышам. Профессиональ яктан үсү дә ошый миңа. Хәзерге вакытта биологияне институт дәрәҗәсендә өйрәнәм.

Катлаулы тормыш юлы миңа сабак бирде. Беренче чиратта бары тик үзеңә генә ышанырга кирәклекне төшендерде. Аннан соң үзеңне яратырга кирәк икән. Башкаларга яхшылык эшлим дип, үзең турында онытырга кирәкми...

СОРАУ-ҖАВАП

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Коръәннең яңа «Казан басмасы» чыкканнан соң, Коръән тәфсирен хәзерге татар телендә нәшер итү планлаштырыла, дигән иде. Ул кайчанрак чыгар икән?

Рәис БИКМУЛЛИН,
Казан.

«Татарстан-24» телеканалында «Төп яңалыклар» программасында туры эфирда сөйләгәндә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, бу елның ахырына без хәзерге татар телендә яңа тәфсир нәшер итәргә телибез, дип хәбәр итте. Аның сүзләренә караганда, хәзерге вакытта Коръәннең татар телендәге алты аңлатмасы – тәфсире бар.

– Әмма аларның барысы да аңлау өчен катлаулырак. Яңа тәфсирне әзерләү буенча эш бара. Басманың яртысыннан артыгы инде әзер, – диде ул.

Коръән басмасы ел ахырына чыгарга тиеш, дип хәбәр итә Татарстан Мөселманнары диния нәзарәте матбугат хезмәте.

Иркутскида «Боярышник» исемле юыну өчен ясалган сыеклыкны эчеп бик күп кеше агуланганнан соң, азык-төлек булмаган спиртлы продукцияне сату тыелды. Бу алымның нәтиҗәләре бармы?

Салих ВӘЛИЕВ,
Чаллы.

Россиядә азык-төлек булмаган спиртлы продукцияне сатуны тыю тагын 60 көнгә озайтыла, дип белдерә Роспотребнадзор матбугат хезмәте. Идарә тармагы китергән мәгълүматларга караганда, 26 декабрь көнне чыккан 30 көнлек тыю тәкъдиме төбәк хакимиятләре тарафыннан хупланган. Бу гамәл легаль һәм намуслы бизнеска начар йогынты ясамаган. Нәтиҗәләргә килгәндә, Роспотребнадзор мәгълүматлары буенча, алдан билгеләнгән 30 көнлек тыю нәтиҗәсендә агулану очраклары – 33 процентка һәм Яңа ел бәйрәмнәре вакытында үлүчеләр саны 65 процентка кимегән.

Казан дәүләт мәдәният институтында Ачык ишекләр көне үткәрелә, дип ишеттек. Ул кайчанрак була икән?

Рания ГЫЙЛЬФАНОВА,
Тәтеш.

28 гыйнварда Казан дәүләт мәдәният институтында Ачык ишекләр көне уза. Чара институтның Концертлар залында сәгать 10.00дә башлана, дип хәбәр итә югары уку йортының рәсми сайты.

Казанда чаңгы базалары төзелә, булганнары яңартыла. Хөкүмәттәгеләрнең республика районнарында шундый базалар булдыру уе юкмы?

Әлфия ГАТИНА,
Кукмара.

2017 елда Татарстанда 11 яңа модульле чаңгы базасы төзергә планлаштырыла, дип хәбәр итә Татарстанның Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы. Моның өчен 66 миллион сум акча бүлеп бирелгән. Алар Казанда, Чаллыда, Алабугада, Кукмара, Әгерҗе, Ютазы, Спас, Саба, Минзәлә, Әлки һәм Әлмәт районында төзеләчәк. Аларның базасында чаңгы узышы буенча спорт мәктәпләре эшләячәк. Монда мәктәп укучылары өчен физик культура дәресләре һәм ярышлар үтәчәк.

Зөядәге ат сарае туристларны көтә

Быел Зөягә килүче туристлар саны, узган елдагы Яңа ел бәйрәмнәре белән чагыштырганда, 295 процент тәшкил итте. 2016 елның 1-8 гыйнвар көннәрендә Зөядә – 11,6 мең, быел исә 34,3 мең кеше кунак булган.

Быел утрау-шәһәрчеккә инде 400 мең кеше килер дип көтелә. 5520 квадрат метр мәйданны биләгән ат сарае территориясендә – заманча этнография комплексында – кунаклар һәрвакыт үзләре өчен кызыклы әйберләр таба. Балалар һәм өлкәннәр өчен уздырылган мавыктыргыч экскурсияләр һәр туристның күңелендә онытылмаслык хатирәләр калдыра. Экскурсияләр танып белү, тарихи, этнографик юнәлешләр буенча үткәрелә. Хәтта урта гасыр интерьерларындагы тарихи уеннарда да катнашырга мөмкин.

Биредәге остаханәдә теләгән һәркемгә балчыктан сыбызгы ясап бирәләр. Монда шулай ук тимерче алачыгы, күн әйберләр эшли торган остаханә, ике кешелек кунак йорты, сувенир кибете, ресторан урнашкан, монда тәкъдим ителгән азык-төлек һәм эчемлекләрне бары тик шушы ресторанда гына татып карарга мөмкин. Әмма барыннан да бигрәк туристларны ат сарае җәлеп итә. Биредәге бахбайларны үз эшенең осталары карый. Атларның һәркайсын әйбәт ашаталар, артык талчыкмасыннар өчен, һәрдаим күзәтеп торалар. Сарайның урта бер җирендә атка атланып йөрү өчен махсус мәйданчык урнашкан. Җәйге чорда – май аеннан октябрьгә кадәр – абзарда биш ат асрыйлар, аларның берсе Чехиядә җитештерелгән биш урынлы каретага җигелсә, калганнары манежда атланып йөрү өчен кулланыла. Биредә теләгән һәркем үзен җайдак ролендә сынап карый ала, яшүсмерләр һәм өлкәннәрне иярдә дөрес утырырга өйрәтәләр. Мондый хис-тойгылар беркайчан да онытылмый. Зөягә килгән һәр кунакны алар гаҗәпкә калдырачак.

Комплекс тантаналы төстә 2012 елның 29 маенда ачылган иде, төзелеш һәм реконструкция эшләренә «Татспиртпром» акционерлык җәмгыяте гаять зур өлеш кертте.

«Ат сарае – ул безнең тарихыбыз һәм мәдәниятебез. Кунаклар һәм, беренче чиратта, балаларыбыз өчен мондый объектлар күп булырга тиеш», – дип белдерде ачылыш тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов.

Комплексны ачу тантанасында «Татспиртпром» акционерлык җәмгыятенә «Яңарыш» фонды исеменнән Мактау хаты тапшырылды. Компания ат сараен торгызуга сизелерлек ярдәм күрсәтте һәм әлеге объектны финанславын бүген дә дәвам итә. Ат сарае «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-шәһәрчеге» проектын гамәлгә ашыру кысаларында сафка басты.

«Татспиртпром» кабул итеп алганда биредәге корылмалар бик ташландык хәлдә булса да, аңа карап кына аларның кыйммәте кимеми. Бу – Успение монастыре ансамблен тулыландырып торган, XVII йөз ахыры-XVIII йөз башы хуҗалык корылмаларының сирәк һәм зур кыйммәткә ия комплексы. Ат сарае корылмаларының бүгенге көндә бик азы гына сакланып калган, ә капка, аран һәм ат абзары тулысынча диярлек юкка чыккан. Совет заманында биредә медицина учреждениеләре эшләгән.

– Ат сараеның табышы зур түгел. Зөя утрау-шәһәрчегенә гаять күп санда туристлар килә. Биредә икмәк тә, коймак та пешерәләр, ярминкәләр дә үткәрәләр. Әлеге урын халык арасында зур популярлык казанды, – дип саный «Татспиртпром» акционерлык җәмгыяте директоры Ирек Миңнәхмәтов.

Ат сарае манежында атка атланып йөрергә, каретага утырып, утрау буйлап сәяхәт итәргә, нәселле атларны ашатырга мөмкин. Һөнәрчелек бистәсе – сувенирлар ясау процессында катнашу, илнең танылган осталарыннан мастер-класслар алу мөмкинлеге дә. Зөягә килгән кунаклар тимерче һәм чүлмәкче һөнәрләренә, акча сугу һәм күнгә басып бизәк төшерү серләренә өйрәнә ала.

ТАРИХИ БЕЛЕШМӘ

Зөя утравында Успение монастыре (аңа 1555 елда нигез салына) сафка басу белән, биредә ат сарае да калкып чыга. Беренче ат сараеның тасвирламасы Зөянең 1565-1567 еллардагы язу кенәгәләрендә китерелә. Ат сарае милкенең өлешчә тасвирламасы, аның параметрлары 1614, 1702, 1739-1741 еллардагы монастырь исемлекләрендә урын алган.

Ат сараеның таш корылмалары һәм диварлары XVII-XVIII йөзләргә карый. XVIII йөз ахырында төзелгән планда ат сараеның конфигурациясе исәпкә алына. Участок монастырьның Изге капкалары каршындагы зур булмаган мәйданчыкка чыга торган көнбатыш тарафындагы капкалар белән әйләндереп алынган. Археологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, иң беренчеләрдән булып ат абзары бинасы, соңрак арбалар куяр өчен лапас төзелгән. Көнбатыш тарафыннан ат абзарына аран орынып тора. Участокның төньяк-көнчыгыш почмагындагы торак бина арбалар кую өчен лапас белән бер үк вакытта төзелгән, әмма XVIII-XIX йөзләрдә үзгәртеп эшләү нәтиҗәсендә сизелерлек зыян күргән.

Реклама 6+

КАЗАНСКИЙ ЗАВОД СИЛИКАТНЫХ СТЕНОВЫХ МАТЕРИАЛОВ
КИРПИЧ от 8,87 р./шт.
5-707-909
5-719-259
www.kzssm.ru
подробности по телефону
ГАЗОБЕТОН от 57,60 р./шт.
ЖБИ изделия
ОТГРУЗКА КРУГЛОСУТОЧНО
Реклама

Бөтен кызыклы мәгълүмат бер урында
www.shahrikazan.com

Чайнворд «Ашамлыклар»



Нияз Бишбалта төзеде

1. Эченә ит, бәрәңге һәм суган салып, почмаклы итеп бөгеп пешерелә торган камыр ашамлыгы.
2. Җиләк-җимеш согына, сөткә һ.б.га крахмал кушып әзерләнгән койка сыман ашамлык.
3. Бодай онынннан пешерелгән төче көлчә, юка.
4. Махсус шампурга кидереп, утта кыздырылган ит кисәкләреннән гыйбарәт ашамлык.
5. Сөт өсте.
6. Сыек камырны кызган табада коеп пешерелгән ашамлык.
7. Кайнатылган сөткә оеткы салып ясалган ашамлык.
8. Атның түш ите.
9. Җиләк-җимешне юка гына җәеп, мич кызуында киптереп ясалган әчкелтем чәй ашамлыгы.
10. Тугылап күпертелгән йомырка агына шикәр оны кушып пешерелгән ашамлык.
11. Ачы камырдан вак-вак итеп ясалган, мич алдында яки плитә өстендә пешерелә торган азык.
12. Сөяксез сыер итеннән, бәрәңге, кыздырылган суган, кишер, помидорны кәстрүлгә салып, шулпа белән пешерелгән ашамлык.
13. Онны ит шулпасы белән катнаштырып, уып, ашка салу өчен (камыр кисәкләре) ясалган ашамлык.
14. Кайнап торган майда йөздереп пешерелә торган юка камыр җәймә.
15. Кызгылт-сары төстәге каты эремчек.
16. Тапалган үпкә-бавыр һәм ярма катнашмасын юан эчәккә салып пешерелгән казылык.
17. Калын кыяк яфраклы тропик үсемлек һәм шуның озынча түгәрәк, эре татлы җимеше.
18. Киптерелгән ипи кисәге.
19. Ачы камырдан мичтә пешерелгән азык; ипи.
20. Озынча формада итеп, иттән яки балыктан турап яки тарттырып пешерелгән ашамлык.

Җаваплар.
1.Өчпочмак **2.**Кесәл **3.**Лаваш **4.**Шашлык **5.**Каймак **6.**Коймак **7.**Катык **8.**Казылык **9.**Как **10.**Күбек **11.**Кабартма **12.**Азу **13.**Умач **14.**Чәлпәк **15.**Корт **16.**Тутырма **17.**Ананас **18.**Сохари **19.**Икмәк **20.**Котлет.

АФИША
30 ГЫЙНВАР– 5 ФЕВРАЛЬ

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

31 гыйнвар «Банкрот» (Г.Камал)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 150-1000 сум

1 февраль «Яшь йөрәкләр» (Ф. Бурнаш)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 150-1000 сум

2 февраль «Бармы ришвәттән дәва?..» (З.Хәким)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

3 февраль «Агыла да болыт агыла...» (Х.Туфан, Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 300-350 сум

3 февраль «Мулла» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 100-1000 сум

4 февраль «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 150-1000 сум

4 февраль «Агыла да болыт агыла...» (Х.Туфан, Т.Миңнуллин)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 300-350 сум

5 февраль «Авыл эте Акбай» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 11.00, 14.00
Билет бәясе: 200-250 сум

5 февраль «Дон Жуан» (Ж.Б.Мольер)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

31 гыйнвар «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов)
Башлана: 18.30

1 февраль «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов, Р.Заһидуллин)
Башлана: 18.30

2 февраль «Назлы кияү» (К.Тинчурин)
Башлана: 18.30

3 февраль «Ефәк баулы былбыл кош» (А.Гыйләҗев)
Башлана: 18.30

4 февраль «Беренче мәхәббәт» (И.Гали)
Башлана: 17.00

5 февраль «Гашыйклар тавы» (И.Юзеев)
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 250-600 сум

ТАТАР ДӘҮЛӘТ «ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

2 февраль «Золушка» (Ш.Перро)
Башлана: 11.00, 13.00

3 февраль «Волшебник изумрудного города» (А.Волков)
Башлана: 11.00, 13.00

4 февраль «Гуси-лебеди» (Л.Кожевникова инсц.)
Башлана: 11.00, 13.00

4 февраль «Бүре җиләге» (Р.Зәйдулла)
Башлана: 15.00

5 февраль «Али-баба и сорок разбойников»
Башлана: 11.00, 13.00

5 февраль «Идет Коза рогатая» (М.Протасова)
Башлана: 11.00
Билет бәясе: 200-300 сум

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ КАЗАН ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

30 гыйнвар «Кичер мине, әнкәй» (Р.Батулла)
Башлана: 18.30

31 гыйнвар «Ильдус+W» (Р.Харис)
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 150-200 сум

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕ
(ПАВЛЮХИН УРАМЫ, 73)

1 февраль «MiraS» инструменталь ансамбле төркеме концерты
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 400-800 сум

4 февраль «Татарча солянка»
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 600-1000 сум

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

Фотохәбәрчеләр Илдар Мөхәммәтҗанов белән Шамил Абдюшевның «Чор һәм шәхес» дип аталган фотокүргәзмәсе эшли.
Керү ирекле (эш көннәрендә)

Информ-хатын



– Менә син, энем, авыл буенча буталып, тегесен-монысын сөйләндереп йөрисең инде, иеме? Аңлыйм инде мин сине, чөнки ипиең шул, газетага язар әйбер кирәк. Әмма, энем, гайбәт, мәгълүмат ягына килгәндә, күңелегез калмасын, сез чүп кенә. Бәлки эшләвен дә тырышып эшлисездер, әмма безнең авылның Сабир Җәмиләсе белән чагыштырганда, чүп сез.

Нигәме? Хәзер аңлатам. Менә, әйтик, сезнең кичә чыккан газетагызда ни дә булса язылган ди. Әмма аны Җәмилә моннан бер атна элек үк белә иде инде. Җитмәсә бөтен нечкәлекләре белән. Каянмы? Шайтаннан. Белә һәм вәссәлам! Үзе авылдан да чыгып йөрми диярлек, ләкин моңардагы мәгълүмат. Ул шәһәрдәге кайсы ашханәдә төйгән бәрәңге ничә сум торганын, кайсы авылга ничә тапкыр автобус йөргәнен, кайсы начальникнең кайда ничә бүлмәле йорт салуын, кемне кайда машина бәрүен – бөтенесен белеп тора.

Монысы ярар инде, шәһәр, район хәлләре дигәндәй. Ә авылга килсә-ә-әң. Монда инде Җәмилә настоящий информбюро. Ярар, кем кызының кемнән корсак төшерткәнен, кемнең сыеры улгәнен, кемнең бәрәңге утамаганлыгын белсен дә ди инде ул. Монысын аның бөтен авыл белеп тора. Ләкин ирләрнең үз хатыннары, хатыннарның үз ирләре дә белми торган нәрсәләрне дә белә бит, каһәр! Менә, әйтик, берәрсе чак кына «сулга каерып» алды ди. Моны беркем күрмәде дә, ишетмәде дә ди. Ә Җәмилә белә, иманы беткере нәрсә!

Ул инде кемнең ничә көн «салып» йөргәне, кемнең фермадан урланган фураж сатып алуы, кемнең хатынын «бәргәләп» алуы ишеләрен әйтеп тә тормыйм – бөтенесе шул җен хатынына билгеле. Бер уйласаң, чистый бер аномаль явление инде ул Җәмилә.

Бервакыт каты гына чирләп китте бу. Куй кибет янына, үз йомышы белән дә стеналарга тотынып кына чыга башлаган. Ире Сабир үзе сөйләде. Ята ди бу шулай урын өстендә ыңгырашып. Беркөнне кичкә таба, ди Сабир, дәшеп китерде дә мине сорый ди: «Сабир, Батәрәй Фатыймасының Чаллыдагы малае бу юлы үзе генә кайткан, ачуланышканнар да, хатыны моны ташлап, аналарына кайтып киткән икән. Әллә иренең зарплатасы аз булгангамы икән?» – дип. Сабир әйтә, баскан урынымда егылып китә яздым, ди.

И-и, ул Җәмиләнең мәгълүмат җыю гаҗәпләрен санаса-аң. Мәсәлән, теләсә кемне эштән куачакларын ул теге кешенең үзенә караганда да алданрак белә, колхоз рәисе Марс Закировның ничә сарыкны ашаганын, ә ничәсен дусларына озатканын, ягъни ул үзе дә хәтерләми торган булса да, Җәмилә төгәл әйтеп бирә. Кемнең кызының кайчан бәбәйләячәген көнендә кадәр диярлек әйтә. Менә шундый информ-хатын ул.

Сезнең газетада, энем, бер генә шундый кеше эшләсә, калганнарының кирәге дә булмас иде. Син дә йөрмә авыл буенча буталып, тегене-моны сөйләндереп. Шыпырт кына бар Җәмилә апаң янына. Сорашырга да кирәкми, үзе сөйли ул.

Илфак ШИҺАПОВ.

5 мәзәк

Хатын:
– Мин бер дә тазармадым! Син ни сөйлисеңдер инде, менә кара, моннан сигез ел элек ничек булса, хәзер дә тап-таман!
Ир:
– Шуңа күрә шарф бит инде ул!

* * *

– Ял мәсьәләсен хатын белән берничек тә хәл итеп бетереп булмый әле.
– Ник ул хәтле аптырадың?
– Беләсеңме, минем Канар утрауларына барасым килә. Ул да миңа иярәм ди...

* * *

Ир белән хатын алтын туйларын уздыралар.
– Дөресен генә әйткәндә, кадерлем, безнең кавышу ул хатадан башланды.
– Ни димәкче буласың инде моның белән?
– Дөресе шул. Бик беләсең килсә, мин ул чагында машина туктатмакчы булып сызгырган идем... Син килеп бастың?

* * *

Чын мәхәббәт ялганыннан ничек аерыла?
Ялганы:
– Миңа синең чәчеңдәге кар бөртекләре үлеп ошый!
Чыны:
– Дивана, кайда бүрегең?!

* * *

– Минем яшьлек пирамидалар төзү чорына туры килде.
– Мисыр пирамидаларымы?
– Юк, финанс пирамидалары.

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ – БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – РАСИХА ГАБДЕЛБӘР кызы ИСМӘГЫЙЛОВА.
© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән авaздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.
РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843). 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1551. Гомуми тираж – 5687.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 669. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843). 562-50-12,
факс: (843). 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы